ӘБИЛӘРГӘ ШТРАФ?

Үзләреннән артканны базарга чыгарып сатучы апа-абыйлар нинди кәеф белән яши?

> 5

МӘГАРИФ ФӘЛСӘФӘСЕ

Киләсе елда дөнья укытучылар көчәре тирәсендә әйләнә башлармы?

> 15

ҮЗЕ ФАЙДАЛЫ, ҮЗЕ БУШКА

Табиблар, өзлегүләрне кисәтү өчен, диспансеризация узарга киңәш итә

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 96 (28869) | Җомга | 8 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҖЫЙДЫМ ҖИЛӘК

АНЫ ҖЫЮНЫҢ ДА ҮЗ СЕРЕ БАР

Быел җиләк вакыты ике атнага соңарды. Шуңа да карамастан, тырышкан кеше җиләкле урынын да, сатып алучысын да таба. Күпләрегез белә: Мамадыш районы авыллары халкы һәр елны Казан – Чаллы юлында җиләк сатып, акча эшли. Җиләк сатып баеп буламы? Җиләкле урыннарны ничек ачыкларга? «ВТ» журналисты үзе дә – профессиональ җиләкче, аны җыю һәм сату серләре белән бүлешә.

> 6

Ишетми калмагыз

Дәүләт Думасы «Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәте турында» законы проектын кабул иткән. Ул балалар һәм үсмерләр белән тәрбия эшен алып баруны күздә тота. Документта билгеләп үтелгәнчә, хәрәкәтнең төп максаты – балаларга һөнәр сайларга ярдәм итү, аларның ялын оештыру, үсү һәм тормышта үз урыннарын табу өчен мөмкинлекләр тудыру, тулы канлы тормышка әзерләү. Депутатлар әйтүенчә, төбәкләр хәрәкәткә күчемле һәм күчемсез милек бирергә тиеш булачак. Хәрәкәт шулай ук чит илләрдә үз вәкиллекләрен ача, халыкара иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итә алачак. Ул үзкөйләнешле коммерциясез оешма булып торачак. Анда, 6 яшьтән алып, югары белем үзләштерүче балигъ булмаган үсмерләр катнашачак.

Сигез ел эчендә – 2014–2022 елларда Татарстанда яңа дүрт торак пункт пәйда булган. Болар – Яңа Әтнә авылы (Әтнә районы), Барсил бистәсе (Питрәч районы), Иннополис шәһәре (Югары Ослан районы), Тарасово бистәсе (Мамадыш районы). Бу хакта юстиция министры урынбасары Мөхәррәм Ибәтов белдерде. Аның әйтүенчә, авыллар һәм бистәләр атамаларының рәсми исемлекләрдәге аермалыклары да, ниһаять, бетерелгән. 2019 елда 21 районда 38 авыл атамасының төрлечә язылганлыгы ачыкланган. Быел 1 гыйнварга 3 атама гына тәртипкә китерелмичә калган булган. Менә хәзер әлеге эш тулысынча тәмамланган.

Татарстан сөт җитештерүчеләр берлеге (Татмолсоюз) сөтчеләрнең тәүге рейтингын булдырган. Исемлеккә узган елдагы эш йомгаклары буенча иң шәп 15 предприятие кергән. Татмолсоюз директоры Денис Пирогов әйтүенчә, рейтинг өч категория – сыерларының баш саны 1000нән артыграк, 500–1000 һәм 500дән кимрәк предприятиеләр буенча әзерләнгән. Аны төзү өчен узган елгы эш күрсәткечләре алынган. Сыерларның баш саны 1000нән артыграк булган предприятиеләр арасында «Красный Восток Агро», «Агросила» һәм «АПК Продовольственная программа» беренче өчлеккә эләккән. Ә инде терлекнең сөт бирүчәнлеге ягыннан Әтнә районы «Таң» кооперативы, Саба районы «ПМК» һәм Әтнә районы «Тукай» предприятиеләре алдынгылыкка чыккан. 500–1000 баш сыер асраучы компанияләр арасында Әлмәт районы Токарликов исемендәге предприятие, Әтнә районы «Мәңгәр», Балтач районы «Кызыл юл» кооперативлары «иң-иң»нәр булып чыккан.

Россия синоптиклары климатның яңа нормаларына күчкән. Хәзер алар һава торышы турында сөйләгәндә, «аномаль» сүзен сирәгрәк кулланачак, дигән сүз. «Аномалия» күпьеллык уртача күрсәткечләргә туры килмәүне аңлата. Россия Гидрометеоүзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд аңлатып үткәнчә, климатның глобаль җылынуын исәпкә алып, яңарак мәгълүматлар буенча башка төрле нормалар исәпләп чыгарылган. Шулай итеп, синоптиклар 1 июльдән шул яңа нормаларга күчкән. Климат нормасын исәпләү өчен 30 еллык чор алына икән. Моңа кадәр 1961 елдан 1990 елга кадәрге күрсәткечләр кулланылган. Хәзер исә 1991 елдан 2020 елга кадәрге саннардан чыгып, һава торышының аномальме-юкмы икәнлеге билгеләнәчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Алты ай эчендә 11 пар игезәк һәм берьюлы өч бала тудыруның 1 очрагы теркәлгән. Гомумән алганда, шушы вакыт эчендә барлыгы 1313 сабый дөньяга аваз салган. Түбән Кама районы ЗАГС идарәсе башлыгы Гүзәлия Сәгыйтова әйтүенчә, районда һәр ел саен уртача 25–30 пар игезәк туа. 2013 ел бигрәк тә «уңдырышлы» булган – 47 пар игезәк нарасый дөньяга килгән.
(e-nkama.ru)

Әлки

Якшәмбе – 10 июльдә Сихтермә-Хузангай авылында чуашларның Уяв бәйрәме гөрләячәк. Анда Кече Мәми авылыннан «Палан» фольклор ансамбле җирле музейга 100 «яшьлек» бишек бүләк итәргә һәм тамашачылар алдында чыгыш ясарга ниятли. Быел бәйрәмдә этник фольклор һәм традицияләрдән тыш, чуаш әдәбияты һәм шигъриятенә дә зур урын биреләчәк.
(«Әлки хәбәрләре»)

Питрәч

Март аенда Көек авылында, «Светлый» торак комплексы территориясендә, өч катлы амбулатория төзелә башлады. Төзүчеләр, нигезен салып, беренче катын күтәргән дә инде. Бу көннәрдә икенче катын күтәрүгә әзерлек эшләре бара. Бирედә барлыгы 22 кеше эшли. Амбулаторияне ел азагына кадәр төзеп, файдалануга тапшыру күздә тотыла. Төзелеш компаниясе вәкиле Евгений Луговкин әйтүенчә, 15 августка кирпеч стенаны тулысынча күтәреп, түбә астына кертү һәм эчке бизәү эшләрен башлап җибәрү планлаштырыла. Медицина объекты «Сәламәтлек саклау өлкәсенең беренчел буынын модернизацияләү» федераль проекты нигезендә төзелә.
(«Алга»)

Мамадыш

Тарихка, халык иҗатына, җыр-биюгә мөкиббән китүчеләр киләсе җомгада – 15 июльдә Урта Кирмән авылына Кирмән җыенына җыелачак. Анда татар халык кәсебе әйберләре һәм хәләл ризык ярминкәләре гөрләячәк, халык җырлары, мөнәҗәтләр, бәетләр башкарылачак, урта гасыр сугышлары күрсәтеләчәк, мастер-класслар эшләячәк.
(«Нократ»)

Әлмәт

«Анимация мәктәбе»ндә яңа «Анимация цехы» мәгариф проекты башланды. Аны, «Татнефть» компаниясе ярдәмендә, Россиянең танылган режиссеры, продюсеры һәм сценаристы Тимур Бекмамбетов оештырган. «Татнефть» хәйрия фонды директоры Ренат Мамин әйтүенчә, проектта өлкәннәр дә катнаша. «Анимация цехы»нда белем алырга теләүчеләргә тест уздырылган. Мультфильмнар төшерү һөнәрен үзләштерергә теләк белдергән 80 кешенең 30ы сайлап алынган. Алар барысы да, 20 мең сумга якын стипендия алып, бушлай укыячак. Курс азагында Бекмамбетовның мультфильмын төшерү өчен 8 кеше сайлап алыначак.
(«Әлмәт таңнары»)

УРТАКЛЫК ЯРДӘМ ИТӘ

tatarstan.ru

Уртак дин, тарихи һәм мәдәни традицияләр... Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, Иран белән үзара мөнәсәбәтләр үсешенә менә шушы үзенчәлекләр дә зур йогынты ясый. Иран Ислам Республикасының Гөлестан провинциясе Губернаторы Али Мөхәммәд Занһане белән очрашуда шулай дип белдерде ул.

Рөстәм Миңнеханов быел республикада Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуын да искәртте. Хәтерләсәгез, май аенда узган бәйрәм чараларында Иран вәкилләре дә катнашты. Аерым алганда, алар «Хәләл экспо» күргәзмәсендә булды. Моннан тыш, Казан Кремлендә Иран сәнгате күргәзмәсе дә оештырылган иде.

«Татарстан һәм Иранның бай тарихи, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләре бар. Хезмәттәшлек буенча зур тәҗрибә тупланган», – диде Татарстан Президенты очрашуда. Рөстәм Миңнеханов бу урында ике арадагы күпергә тузан төшмәвен, эшлекле сәфәрләрнең даими рәвештә оештырылып торуын искәртте. 2018 елда Казанга Ибраһим Рәисинең килүен дә искә алды ул.

Очрашуда Иранның Казандагы Генераль Консуллыгының күпьеллык эше, Сәүдә хезмәттәшлеге турында меморандум, шулай ук Татарстан белән Иран арасында актив хезмәттәшлекнең дә үзара хезмәттәшлек үсешенә ярдәм итүе ассызыкланды. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, пандемиягә кадәр Тәһран – Казан туры һава юллары эшләде. Төрле илларда Татарстанның «КамАЗ», «Татнефть», «Казан вертолетлар заводы» кебек оешмалары төрле илларда Иранда үз проектларын тормышка ашырды. Соңгы елларда ике арада фән һәм мәгариф өлкәсендә дә хезмәттәшлек үсә. Татарстан һәм Иранның кайбер югары уку йортлары арасында килешү төзелгән. Бүген республикада 765 Иран студенты белем ала.

Рөстәм Миңнеханов авыл хуҗалыгы, нефть химиясе, машина төзелеше, сәламәтлек саклау өлкәләрендә дә үзара хезмәттәшлекне көчәйтү өчен мөмкинлекләрнең күп булуын искәртте. «Транспорт логистикасы мәсьәләләре аеруча мөһим. Сез географик яктан уңайлы җирдә урнашкан. Бу мөмкинлекне яхшылап өйрәнергә кирәк дип саныйм», – диде Рөстәм Миңнеханов. Аның бу тәкъдимен Али Мөхәммәд Занһане дә хуплады. Гөлестан провинциясенең Татарстан белән сәүдә мөнәсәбәтләрен яхшыртырга теләвен дә искәртте ул.

Дәүләт Советында

ЯЗНЫҢ СОҢГЫ УТЫРЫШЫ

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының язгы сессиясендәге соңгы – утыз өченче утырышы 14 июльдә үткәреләчәк. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 19 мәсьәләне, шул исәптән республиканың 3 законы проектын, 6 федераль закон проектын һәм Россия төбәкләре законнар чыгару органнарының ике мөрәҗәгатен карап тикшерергә җыена.

Дәүләт Советы Рәисе көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карауга керешкәнче, гадәттәгечә, соңгы вакытларда республикада булып узган әһәмиятле вакыйгаларны билгеләп үтте. Фәрит Мөхәммәтшин сайлау кампанияләре чорында кешеләрдән җыелган тәкъдим-наказларны үтәүгә аерым тукталды.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина әйтүенчә, утырышның көн тәртибенә кертелгән ике республика законы проекты (күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү һәм урманнардан файдалану турында законнарга үзгәрешләр кертү хакында) беренче укылышта каралачак. Җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж йөртүне оештыру турында законга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проекты исә икенче укылышка әзерләнгән.

Шулай ук Дәүләт Советының Дәүләт Думасына ике закон инициативасы (Административ хокук бозулар турында Россия кодексына, мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында федераль законга үзгәрешләр кертү буенча) карап тикшереләчәк. Биредә сүз Россия субъектларының дәүләт символларына карата ихтирамсызлык өчен административ җаваплылык билгеләү турында бара.

Язгы сессиянең соңгы утырышы кысасында Әлки районы Сихтермә-Хузангай авылы исемен үзгәртү турында Дәүләт Советы карары проекты буенча фикер алышу да булачак әле. Исегезгә төшерәбез: Әлки районы советы Сихтермә-Хузангай авылында яшәүчеләр исеменнән Дәүләт Советына авылның тарихи – Сихтермә (чуаш телендә «бишек» дигәнне аңлата) исемен кире кайтаруны сорап хат юллаган иде.

«Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе утырышның көн тәртибенә авыллар һәм бистәләрдә яшәүче аналарга өченче баласын тудырганнан соң бер тапкыр түләү билгеләү зарурилыгы турында Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга Дәүләт Советы мөрәҗәгатен карап тикшерүгә кертергә тәкъдим иткән.

Моннан тыш утырышта парламентның беренче яртыеллыгындагы эшенә йомгак ясалачак. Бу җәһәттән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның чыгышы көтелә.

Президиум утырышында шулай ук Татарстан Үзәк сайлау комиссиясен оештыру мәсьәләсе каралды. Быел сентябрь аенда аның вәкаләтләре срогы чыга. Үзәк сайлау комиссиясе 14 кешедән торырга тиеш. Җидесен – Дәүләт Советы, калганнарын Татарстан Президенты билгели.

ГАИЛӘ НЫКЛЫГЫН НИЧЕК САКЛАРГА?

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҺӘР ЙОРТТА ҮЗАРА АҢЛАШУ ЯШӘСЕН!

8 июль – Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне уңаеннан Татарстан Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА татарстанлыларга котлау белән мөрәҗәгать итте.

«Россия Федерациясе Президенты Указы белән 2022 елда билгеләнгән бу дәүләт бәйрәме традицион гаилә кыйммәтләрен саклауга, балалар һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүгә юнәлдерелгән.

Нәкъ менә гаилә – безне бер-беребезне яратырга һәм хөрмәт итәргә, якыннарыбызны кайгыртырга өйрәтә, авырлыкларны җиңеп чыгарга көч бирә. Гаиләдә өлкәннәрдән кече буынга әхлакый нигезләр, туган тел, милли һәм мәдәни традицияләр тапшырыла.

Гаилә тарихларының һәм кеше язмышларының төп елъязмачысы булып, 100 елдан артык вакыт дәвамында гражданлык хәле актларын теркәү органнары тора. Безнең республикада ГХАТ органнары халыкның гражданлык-хокукый статусын үзгәртүне теркәп кенә калмый, ә дәүләт гаилә сәясәтенең актив катнашучысы булып тора, демографик халәтне күзәтә.

Елдан-ел иҗтимагый гаилә хәрәкәтенең популярлыгы һәм ихтыяҗы арта бара, аның кысасында масштаблы конкурслар һәм фестивальләр, гаилә тормышы юбилярларын хөрмәтләү чаралары үткәрелә, республиканың атказанган гаиләләренә «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медальләре тапшырыла.

Сезне искиткеч гаилә бәйрәме белән тәбриклим, һәр йортта гаилә учагының җылысы, үзара аңлашу һәм матур мөнәсәбәтләр яшәсен. Гаиләләрдә тынычлык һәм иминлек хөкем сөрсен, күңелле балалар көлүе яңгырасын!» – диелә котлауда.

Президент Владимир Путин, гаилә кыйммәтләрен саклау, яшьләрне рухи яктан тәрбияләүне күздә тотып, 8 июльне рәсми рәвештә Гаилә көне дип игълан итте. Алга таба гаилә институтын да ныгытырга җыеналар. Дәүләт Думасына шул хакта закон проекты кертелгән. Ә сез гаилә ныклыгын ничек саклыйсыз?

Хәлил ШӘЙХЕТДИНОВ, Татарстан спорт министрының беренче урынбасары:

– Бу – бик мөһим мәсьәлә. Гаилә ныграк булган саен, республика, ил дә тотрыклырак була. Бүген балаларга тәрбия, игътибар җитеп бетмәвен күрәбез. Кызганыч, гаиләнең ныклыгы җитмәү сәбәпле, күбесе таркала. Без үскәндә, җитмәүчелек күп иде. Әмма гаиләләр бик нык көчле иде. Өйләр кечкенә булса да, бала-чага белән тулы иде. Хәзер өйләребез зурайды, тик күңелләребез тарайды. Шәһәрләрдә, авылларда зур-зур ташпулатлар, анда нибары 1–2 бала тәрбияләнә. Минем өчен гаилә ул – барысы да. Ирешкән уңышларымда гаиләмнең, хатыным Ландышның өлеше бик зур. Мин гаиләне туендыру, торак мәсьәләсен кайгыртсам, хатыным кызларыма тәрбия бирде. Гаиләнең ныклы булуы – ир кеше өчен бигрәк тә зур бәхет. Бергәләп гаилә бәйрәмнәре уздырабыз. Атна ахырында мунча кереп, шашлык пешереп, рәхәтләнеп сөйләшәбез. Әти кайтмыйча, әни безне табын янына утыртмый иде. Бу гадәт безнең гаиләдә дә саклана.

Минзифа ТАҖЕТДИНОВА, Чүпрәле районы укытучысы:

– Гаилә көнен билгеләү дә, әлеге институтны ныгыту да кирәк. Ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр күп, аларга булышсыннар иде. Ирем Шамил белән бергә яши башлавыбызга – 28 ел. Ике бала тәрбиялибез. Бер-беребезгә «кадерлем», «бердәнберем» дип дәшәбез. Бу – күз буяу түгел, күптәннән килгән гадәт. Өйләнешкәндә булган мәхәббәтне югалтмыйча сакларга тырышырга кирәк. Бер-береңне аңларга, хыянәт итмәскә... Хыянәтне кичерә белергә кирәк, дигән сүз бер дә дөрес түгел. Ир белән хатын бер-берсенең күзенә карап торганда, Аллаһы Тәгалә дә аларга сөеп карый. «Ир хатынның кулыннан тотса, хатынның бармак араларыннан гөнаһлары коелыр» дигән хәдис бар. Кешегә ярыйм дип, гаиләгә игътибар итмичә яшәмәгез. Ике яктан да әти-әниләрегезне хөрмәт итегез. Минем өчен ир сүзе – закон. Күп нәрсә хатын-кыздан тора. Хатыннар дорфа булса, ирләр дә тупас булачак. Ирләр тупаслыкны яратмый. Гаиләләр хәзер иркенлек яклы. Әгәр иркенлек яратасыз икән, өйләнмәгез, кияүгә чыкмагыз. Шундый гаиләләр аерылыша да инде. Бергә кавышкансың икән, «мин» дигән нәрсә бетте. Бер-берең хакында уйлап, «без» дип яшисе. Мин балаларга, тормышта кызык эзләп яшәмәгез, дип өйрәтәм. Алдыгызга карагыз да тырышып укыгыз, эшләгез, дип әйтәм. Кызык эзләсәң, аны җиткереп булмаячак, күңел көн дә шуны таләп итәчәк.

Гөлүсә БАТТАЛОВА, язучы:

– Ирем Алмаз белән өч бала тәрбиялибез. Гаиләдә махсус традицияләребез юк, гади генә тормыш итәбез. Иң мөһиме: ир белән хатын бер-берсен аңларга тиеш. Минем өчен аңлау белән ярату бер дәрәҗәдә санала. Еллар үткән саен, ярату да, кадер дә арта гына бара. Аның яшь вакытта аңлап бетермәгән ниндидер матур бизәкләре барлыкка килә. Мизгел эчендә кабынып сүнә торган ярсу хисләр бетә, сабырлык ныгый, тыйнаклык арта. Безнең гаиләдә бер-беребезне кысага кертү, чикләү дигән нәрсә юк. Беркайчан да телефоннарыбызны тикшермибез. Бер-береңә ышанасың икән, нигә тикшерергә?

Бик матур яшь парлар аерылыша. Бер караганда, аларның әллә ни проблемалары да юк кебек, вак-төяк өчен ачуланышалар. Менә бу статистика кимесен иде. Әмма дәүләт аны ничек көйләр, белмим. Элек яңа өйләнешкән парларга, әйтик, заводта күпмедер эшләгәннән соң фатир биргәннәр. Укып бетергәч, эш урыны була дип ышанып торган алар. Яшәү урыны булу бик мөһим. Ипотека алсаң, аны 20–30 ел түлисе бит. Яшь гаиләләр өчен дәүләт программалары булганда, яшьләргә тормыш башлау җиңеләер иде.

Лилия ГОСМАНОВА, Әгерҗе районы ЗАГСы белгече:

– Гаилә көнен билгеләү турындагы хәбәрне ишеткәч, бик сөендем. Ярдәм югарыдан кирәк. Ярый, календарьда кызыл дата булмасын, әмма бу көн кеше күңеленә керә бит. Электән корылган төпле гаиләләр шактый. Без моңа архивлар актарганда игътибар итәбез. Яшьләр арасында күп дип әйтә алмыйбыз. Озак еллар бергә яшәүчеләрне билгелибез. Яшьләр көнендә дә 5–10 ел торган лаеклы гаиләләргә дә грамоталар бирәбез. Бу бит – башкаларга да үрнәк. Яшь парларның никахларын теркәгәндә, көмеш, алтын туйларын билгеләп үтүче юбилярларны да чакырабыз. Дөрес, үзләре риза булса. Алар яңа өйләнешүчеләргә үз гаиләләренең озын гомер серен чишә. Ярату сүзләрен кызганмагыз. Әгәр син хатынының гомерлек яр итеп сайлагансың икән, аны сакла, югалтма! Беренче очрашу мизгелләрен ешрак искә төшерегез.

Сәрия МИФТАХОВА сорашты

Өченчесе акча китерер

Татарстанда беренче балаларын табучыларның уртача яше 29га якынлашкан. Димәк, хатын-кызлар икенче һәм аннан соңгы балаларын тагын да соңрак алып кайта дигән сүз. Бу турыда Дәүләт Советында Социаль сәясәт комитеты утырышы вакытында билгеле булды.

Утырышта чыгыш ясаган Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры, социология фәннәре докторы Чулпан Илдарханова әлеге мәсьәләнең җитдилегенә игътибар итте һәм нәтиҗәле чаралар күрергә кирәклеген әйтте. Узган елның сентябрендә үткәрелгән халык санын алуның беренчел мәгълүматлары на караганда, Татарстанда 4 млн 5 мең кеше яши. Чулпан Илдарханова билгеләп узганча, үлем-китемнәр күп булса да, кайбер күрсәткечләр уңай нәтиҗә биргән.

– Мәсәлән, очраклы рәвештә алкоголь белән агуланудан үлүчеләр саны кимегән: 2020 елда 100 мең кешенең 2сенең үлем сәбәбе нәкъ менә шул булган. Бу мәсьәләдә иң кызганыч күренеш 2004–2005 нче елларда теркәлгән иде. Ул вакытта 100 мең кешенең 10ы исерткеч эчемлекләр эчеп харап булган, – диде ул.

Утырышта катнашкан җитәкчеләрне борчыган төп мәсьәлә халык саны буенча уңай динамикага ирешү мөмкинлеге иде. Шуңа күрә фикер алышулардан соң комитет әгъзалары Дәүләт Советының Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга мөрәҗәгатен карады. Аерым алганда, алар авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга өченче бала туганда бер тапкыр түләнә торган түләүне билгеләргә тәкъдим итә. Әлеге инициатива белән «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзалары чыгыш ясады, профильле комитет әлеге инициативаны хуплады.

Алар фикеренчә, әлеге түләүләр федераль бюджет акчасы исәбеннән хатын-кызларның яшен чикләмичә бирелергә тиеш. «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиева сүзләренә караганда, авылда хатын-кызларга ярдәм итү мәсьәләсе Идел буе федераль округының закон чыгару җыелышлары депутатларының дискуссия мәйданчыгы утырышларының берсендә күтәрелгән. Әлеге тәкъдим Идел буе федераль округының барлык төбәкләре тарафыннан да хупланган.

Билгеле булганча, 2018 елдан республикада авыл җирендә яшәүче хатын-кызларга бер тапкыр түләнә торган түләүләр билгеләнде. Аның күләме беренче бала туганда (25 яшькә кадәрге хатын-кызларга) – 50 мең сумны, өченче бала (29 яшькә кадәрге хатын-кызларга) туганда 100 мең сумны тәшкил итә. Инде беренче нәтиҗәләр дә бар. Шушы вакыт эчендә республика авылларында 8,8 меңнән артык бала туган, беренче бала туганда түләүләр саны – 6, өченчесе туганда 27 процентка арткан. Әлеге максатларга республика бюджетыннан барлыгы 518,8 млн сум акча җибәрелгән. Татарстан буенча тулаем алганда, өченче һәм аннан соңгы балаларның туу өлеше бу вакыт эчендә 3,5 процентка үскән, 2021 ел нәтиҗәләре буенча 24,8 процентны тәшкил иткән.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Байдын кызын алаем...»

Мәскәү телевизион каналларының берсеннән тапшыру бара иде. Яшь кенә бер казах егете:

«Тегедек, тегедек, тегедек, тегедек,

Байдын кызын алаем...» – дип җырлый. «Тегедек» дигәне атта чабуны аңлату инде, тик кенә Байдын кызын телгә алуы сәер тоелды. Нүжәли казах егете Америка Президенты кызына баш югалтып гашыйк булган? Күптән түгел Байденның Эшли исемле кызына бәйле бер гауга чыгуын ишеткән идем. 41 яшьлек Эшли кунакханә номерында матрас астында көндәлеген онытып калдырган булган да, аны бер хатын табып, Такер Карлсон дигән журналистка тапшырган. Көндәлектә исә Эшли бала чагында әтисе Джо Байден белән бергә душта коенулары турында язган булган. Журналист, әлеге хәлне Америка лидерының җенси бозыклыгы, азгынлыгы санап, полициягә мөрәҗәгать итәргә булган. Шул ук вакытта, әтисе белән душта юыну турында нәкъ менә Эшли язганлыгыннан шикләнгән дә журналист. Сайлаулар алдыннан кемдер Джон Байденга этлек эшләргә теләгән булырга мөмкин дип уйлаган. Икеләнер өчен сәбәпләр дә булган үзе. Эшли, мәсәлән, бик яшьли ирләргә тартылуы, секс белән шөгыльләнүе турында да язган булган.

Мин, дөньялар белән бергә башлар да буталган чак булып, казах егете әллә чыннан да Эшли Байденга гашыйк булган микән, дип уйладым. Бәлки, әтисенең байлыгына да кызыккандыр. Белүемчә, Казахстанда тормыш дәрәҗәсе әллә ни югары түгел. Кустанайда Ренат исемле танышым яши. Югары белемле юрист ул, хәрби дәрәҗәсе дә бар, отставкадагы полковник. Әмма аның пенсиясе, безнең акчага күчергәндә, нибары 6 мең сум иде, минекеннән ике мәртәбә ким. Казахстанда яшәүчеләрнең бердәнбер күңел юаткычлары – әйбер, бигрәк тә бензин, азык-төлек арзан иде анда. Хәзер ничектер, белмим. Әмма соңгы вакытта Казахстанда булып узган чуалышлар андагы тормышның «кәнфит» булмавын раслый.

Казахларның тормышын тәнкыйтьләмик, үзебездә дә «коммунизм»га ерак әле, әмма «илдә чыпчык үлми» дип, рәхәтләнеп яшәп ятабыз. Бай кешеләрнең кызларына да кызыкмыйбыз, безгә үзебезнеке таман.

Бер-ике көннән соң Мәскәү телевидениесеннән теге тапшыруны кабатлап күрсәттеләр. Башыннан ук карый алмадым, ә менә казах егетенең теге җырын тагын бер кат тыңларга насыйп булды:

«Тегедек, тегедек, тегедек, тегедек,

Байдын кызын алаем...»

Аңа кушылып үзем дә җырладым. Эштә дә, танышларым янында да такмаклап йөри башладым мин аны. Үземнең авыз ерык.

Шуннан берсе: «Нигә көләсең?» – ди.

– Көлми, әнә бер казах егете Джо Байденның кызына гашыйк булган. Америкага китмәкчедер, пажалый, Эшли Казахстанга кайтмас, – мәйтәм. Теге танышым: «Мин дә карадым ул тапшыруны, бит казах егете Байден кызын түгел, байның кызын алаем, дип җырлый, «байның» сүзе казахча «байдың» була, син аны ялгыш ишеткәнсең», – диде.

Ерылган авыз шундук ябылды. Тик танышым алдында сер бирәсе килми. «Шулай дип уйлаган идем аны», – дигән булдым. Ә эчтән генә: «Нәрсәгә баш катырам соң әле! Ник чукынып китми Байдены, аның кызы Эшли», – дип үземне тынычландырдым. Минем үземә Америкасы, американкасы да кирәк түгел, яшәсен мишаркам! Үзен кыстырып язганны җене сөйми, шуңа күрә хатынымның исемен дә, Әлмәт районының Елховой авылында үскән мишәр кызы икәнен дә язып тормыйм, белми торсыннар әле.

Ә менә кайвакыт:

«Тегедек, тегедек, тегедек, тегедек,

Мишәр кызын алаем...» –

дип такмаклап куям.

УРТА АЗИЯНЕ СЕЛКЕТКӘНДӘ

СӘЯСӘТТӘ БАРЫ ТИК БУ КӨН ГЕНӘ БАР

Бүген Җир шарында бара торган катлаулы процесслар уйланырга мәҗбүр итә, чөнки социаль тетрәнүләр кайда гына бармасын, безнең тормышка да тәэсир ясый. Иң мөһиме һәм аянычы: турбулентлык безнең киләчәгебезгә яный, ыргылып һәм ашкынып, безнең алдагы көннәребезгә бәреп керә. Һәм бер дә җиңел тормыш вәгъдә итми. «Нишләргә һәм ничек яшәргә?» дигән сорау әлегә куелмады, әмма киләчәк көннәрдә үзенең бөтен аяусызлыгы һәм катылыгы белән куелачак әле ул. Алдан ук әйтеп куйыйк: бар ул сорауның җавабы, әмма зур сикәлтәләр аша үтми торып, җавапны аңлап булмаячак.

Әлегә без киләчәктәге бөек түнтәрелешнең беренче билгеләрен генә күзәтәбез. Соңгы каракалпак фетнәсе – шул билгеләрнең берсе һәм әһәмиятлесе. Әйтик, зур халык массаларының урамнарга чыгуы бүгенге Көнбатыш өчен дә сирәк күренеш түгел. Фетнә ешлыгы анда да арта бара. Бу юллар язылганда, Нидерландта (Голландия) фермерлар бунты көчәя, мәсәлән... Ләкин голланд фермерларының полиция сафлары белән бәрелеше безне әллә ни кызыксындырмый, полиция хезмәткәрләренең, гражданнар киемендә фетнәче фермерлар рәтенә басып, провокация ясарга тырышулары да артык гаҗәпләндерми. Көнбатыш фетнәчеләре социаль таләпләр генә куялар, дәүләт машинасына да янамыйлар, системаны җимерергә ихтимал адымнар да атламыйлар. Аннан соң Көнбатыш протесты ул – нигездә, тыныч протест, кан коюларсыз гына бара. Соңгы көннәрдә генә булып узган каракалпак фетнәсе искәртә: мөселманнар яшәгән төбәкләрдә халык күтәрелеше авыр һәм әрнеткеч нәтиҗәләргә илтә. Кыямәт алдыннан мөселман дөньясында башланачак зур фетнәнең зур куркыныч тудырачагын Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәсәлләм) әйтеп калдырган. Ул аны (фетнәне) күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төнгә тиңли. Бөек түнтәрелеш вакытында болганчыклык шулкадәр каты була: мөселманнар хакыйкатьнең кайда икәнен күрә алмыйлар. Иманны югалту куркынычы туа. Һәм югалтучылар күп тә була. Аллаһның илчесе ул фетнәгә катнашмаска чакыра: кулыңдагы кылычны (коралны) ташка бәреп ватарга өнди. Үзара үтерештә катнашканчы, үлемең яхшырак дигән фикер уздыра.

Ислам дөньясында ун елдан артыграк элек башланып киткән фетнәгә әйләнеп карыйк. Ливиядә халык тынычлык тапмады, Каддафины үтерү ливиялеләргә кан коюларның чираттагы зур сериясеннән башка берни дә бирмәде. Тунис һаман да идарәнең оптималь формасын таба алмый азаплана, социаль проблемалар беркая да китмәде. Мисыр элеккедән дә катырак диктатура кочагында. Сүрия зур тартыш мәйданына әверелде. Анда мөселманнарның үзара тартышучы күпсанлы төркемнәре, көнбатышлыларның яхшы коралланган гаскәрләре үзләренең нинди бурыч үтәргә тиешлекләрен дә оныттылар...

Бу фетнәләр сериясендә Урта Азия тартышы аерым бер урын алып тора. Амудәрья һәм Сырдәрья елгаларының төньягында яшәүче мөселман халыкларының якын киләчәктә дөньякүләм әһәмияткә ия зур тарихи миссияләре бар. Бу – зур байлыклар тупланган төбәк. Җир шары халыклары, исраф итмичә, гадел тормышта яшәсә, шул җирләрнең табигый байлыклары белән генә дә бик җиңел алтын гасырга күчә алырлар иде. Бүген иртән генә telegram-каналларның берсендә актив язучы аналитик: «Хәзерге сугыш җирләр өчен дә, байлыклар өчен дә түгел, акыллар һәм йөрәкләр өчен бара», – дип язып куйды. Сугыш дигәндә, без ракеталардан һәм барражирлаучы кораллардан атып үтерешүләрне генә түгел, киң мәгълүмат сугышын да күз алдында тотабыз. Менә шул мәгълүмат сугышы башкасын әзерли дә инде. Башта телеканаллар һәм интернет «ата», аннан соң гына туплар һәм танклар хәрәкәткә килә. Эстрада сәхнәсе, матур әдәбият, күпсанлы газета-журналлар катнаша хәлиткеч сугышта.

Инде хәзер яңа гына яңгырап үткән каракалпак фетнәсенә әйләнеп кайтыйк. Әйдәгез, сүзне Лукашенкога бирәбез. Бүген изоляциядә булса да, белорус диктаторы халыкара лидерлар клубында аерым урын тота. Безгә генә ул ил җитәкчеләре үзара талашта һәм ызгышта булып күренә. Чынлыкта алар бер табактан ашыйлар. Шулай булгач, аларда мәгълүмат та күбрәк. Лукашенко исә Казахстанда гыйнвар фетнәсе булып узуга ук, чиратның Үзбәкстанда икәнен кисәтте. Хәзер ул үз фаразының чынга ашуы уңаеннан тантана итә: «Үзәк Азия безнең шикелле үк ике ут арасында калды. Бер яктан – европалылар, амерерикалылар, икенче яктан – Үзәк Азиягә нык булышучы Кытай... Һәм менә Үзәк Азиядә каты бәрелеш булачак. Якындагы киләчәктә көтегез», – диде ул каракалпак фетнәсе уңаеннан. Лукашенко фаразы буенча, Нукустагы канкоеш – вакыйгаларның соңгысы түгел, прологы гына, ягъни башы.

«Нукустагы мәйданга бикфорд шнурын кем сузды?» дигән сорауга рәсми сәясәтчеләр, «тышкы көчләр» дип җавап бирергә тырышалар, әмма ул «көчләр»нең кем икәнен берәү дә атамый. Ярый, шулай булсын ди. Үзбәкстан Конституциясенә үзгәрешләрне кем язды? Үзбәк парламенты. Мөгаен, президент Мирзиоев кушуы һәм контроле астында язылгандыр статьяларның референдумга чыгарылачак варианты. Тавыш бит нигездә Каракалпак Республикасының суверенитетына янаучы үзгәрешләр кертергә ниятләгәч чыкты. Фетнә мәйданы бик тиз җыелды, кан да коелып өлгерде. Бернинди тышкы көч тә ул арада гына халыкны котыртып урамнарга чыгара алмый. Читтәге көчләр, әлбәттә, катнашырга тырышачаклар, әмма алар коткыны эш башлангач кына салалалар мондый очракта. «Тышкы көч» картасын файдалану рәсми хакимиятләргә үз хаталарын яшерү, җаваплылыктан качу һәм, хәл кискенләшсә, читтән ярдәм чакыру өчен генә кирәк. Әмма шулай да бар ул «тышкы көч». Каракалпак ярасыннан әле һаман да кан саркый, төп мәсьәлә – төбәкнең суверенитеты мәсьәләсе каракалпаклар теләгәнчә хәл ителде, әмма конфликтны дәвам итәргә һәм киңәйтергә тырышучы көчләр һаман да үз эшләрен эшли. Үзбәкстан туфрагына Әфганстаннан ут ачылу, снарядлар төшеп ярылу турында хәбәр чыкты мәгълүмат кырына. Атучылар «Талибан*» түгел. Рәсми әфган хакимиятләре белән Ташкент бу мәсьәләдә уртак фикердә: көймәне чайкалдырырга теләмиләр. Әмма факт факт булып кала: чайкалдырырга теләүче көч бар. Ул көч Байден да, әфган лидерлары да, Путин яисә Кытай компартиясе дә түгел. Әрдоган түгел дә түгел инде, чөнки Әнкара харизматигына Урта Азиядә тынычлык мөһим, дивидендларны ул рәсми хакимиятләр белән уртак хезмәттәшлек аша алырга тели. Кремльдә дә, мәсәлән, Үзәк Азиядәге тектоник үзгәрешләрдән куркалар, анда статус-квоның, ягъни агымдагы тотрыклы вазгыятьнең саклануын телиләр. Шуңа карамастан, вазгыять чайкала һәм чайкалачак. Бүген аркадаш булган лидерлар иртәгә аркага пычак кадарга да мөмкиннәр. Хәзерге дөньяда дуслык – вазгыяти дуслык, дошманлык та шулай ук. Бүгенге дошманнар иртәгә дус, дуслар дошман була ала. НАТО саммитыннан соң чит ил журналистларының берсе Әрдоганга сорау бирде: «Элек Байден сезнең ачуны чыгара торган сүзләр сөйли иде. Әмма сез кичә яхшы дуслар кебек күрендегез. Нәрсә үзгәрде?» «Бу бит – сәясәт, – диде Әрдоган җавабында. – Сәясәттә бүгенге көн генә бар. 24 сәгать эчендә сәясәттә күп нәрсә үзгәрә ала. Без аны шулай бәяләргә тиешбез».

Әйе, әйе, Урта Азиядәге хәлләргә дә нәкъ шулай бәя бирергә туры килә. Бүгенге тотрыклылык иртәгә зур чайкалу белән алышынырга мөмкин. Гыйнвар башында Казахстан фаҗигасе уйналып тәмамлангач, мин «Ватаным Татарстан»да: «...гыйнвар башындагы вакыйгалар – казах драмасының беренче акты, дип белдерә алабыз», – дигән идем. Кызганыч ки, Нукус канкоешы турында да шуны кабатларга мәҗбүрмен. Бер җепнең сәйләннәре болар барысы да һәм тартыш ул җеп өзелгәнче барачак. Фараз шундый: Урта Азиядәге зур тетрәнүләр Украина конфликтыннан алдарак тәгәлләнәчәк. Россия ул уңайдан үзенең көньяк чикләрендә зур проблемалар белән очрашыр һәм, Лукашенко әйткәнчә, «ике ут арасында» калыр, мөгаен. Вакыйгалар фаталь рәвештә шул якка таба хәрәкәт итә...

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

* Россиядә тыелган экстремистик оешма.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БАЗАР ЗАКОННАРЫ

Үзләреннән артканны базарга чыгарып сатучы апа-абыйлар нинди кәеф белән яши? Моны без башкаланың берничә базарына чыгып ачыкладык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мәскәү базары

Беренче тукталышыбыз Мәскәү базары булды. Сәгать тугыз тулып киткәндә, базар гөрли иде инде. Бу көннәрдә бирердә иң популяр товар ул – әлбәттә, җиләк. Аннан соң – яшел тәмләткечләр һәм яшелчәләр.

Галия апа базарның эченә узмыйча, керү юлында гына урнашкан. Үз бакчасында үстергән җиләкләрен сатарга чыккан. Бераз гына яшел тәмләткечләре дә, йомыркасы да бар. Бакча җиләгенең бер стаканын 180 сумга тәкъдим итә.

– Кызым, мин бу урында беренче көн генә утырам әле. Гомумән, базарга сату белән сирәк йөрим. Башка вакытта юлның каршы ягына чыгып утыра идем, тик анда йөрүче аз. Урын өчен акча сораганнары юк иде, – диде ул.

Иң кызыгы – базарның эчендә. Монда чиләк-чиләк утырган кып-кызыл җиләк исләреннән башлар әйләнерлек. Каен җиләге дә, урман җиләге дә, бакча җиләге дә күп, җаның кайсын тели, сайла да ал. Сайлау мөмкинлеге күп булгач, халык та рәхәтләнеп, иркенләп йөри. Әле бер сатучы, әле икенчесе янына туктала, сатулаша.

– Хатыным җиләк җыярга бөтенләй яратмый. Җыя торган урыннарын да белмибез. Шуңа күрә җиләкне ел да сатып алып кына ашыйбыз. Артык күп алмыйбыз. Туйганчы ашыйбыз да, калганын я болай гына, яки шикәр белән болгатып катырып куябыз, – диде үзен Александр дип таныштырган әңгәмәдәшебез.

Базарда сату итүчеләрнең күпчелеге – Мари Иле һәм Чувашиядән килүчеләр. Менә 75 яшьлек Мария түти дә быел беренче тапкыр җиләк сатарга чыккан. Каен һәм урман җиләге белән тулган чиләкләре тезелеп киткән иде. Төрле үләннәр дә алып килгән. Үзен Чувашиядән дип таныштырды.

– Шушы кадәр җиләкне ничекләр җыеп бетерәсез? – дим сорыйм аңардан.

– Мин генә җыймыймын бит. Балалар иртән үк китеп җыялар. Алар өйрәнгән инде, куллары эшкә ятып тора. Безнең авыл халкы шушы чорда күп акча эшләп кала. Быел җиләк бик күп. Озак сатачакбыз әле. Бүген җиләк белән беренче тапкыр килдем. Кышын да, җәен дә шушында инде мин. Кышын салатлар, кайнатмалар алып киләм. Монда шунысы яхшы: без – өлкәннәргә сату бушлай.

– Бу кадәрле җиләкне алып бетерәләрме соң?

– Берсе дә калмый. Ел саен бездән генә ала торган сатып алучылар булгач, тагын да яхшы.

Тагын бер сатучы янына тукталдык. Анысы исә Мари Иленнән булып чыкты. Ул да күп итеп җиләк алып килгән иде.

– Быел җиләк күп, тик җыючылары тагын да күбрәк, – дип елмайды әңгәмәдәшебез. – Без җиләкне үзебез җыябыз. Шуңа күрә көнаралаш кына киләбез. Көненә 35–40 литр җиләк сатабыз. Бу – 15 мең сум акча дигән сүз.

Үзәк базар

Икенче тукталышыбыз башкаланың данлыклы Үзәк базары иде. Монда да сатучылары да, сатып алучылары да күп. Күпчелек кеше әлеге дә баягы җиләк, яшелчәләр тирәсендә бөтерелә. Һавада – тәмле исләр.

Бер апаның: «Кызым, мин Дөбьяздан килдем. Үземнең бакчамда үскән җиләк. Аласыңмы? Килограммы 300 сум гына. Бик тәмле бит», – дигән тавышына игътибар итеп, янына барасы иттем. Апа бирердә бик сирәк була икән. Урын өчен 150 сум акча түләгән. Чиләкләре дә күп түгел иде. Икенче әйләнеп килүемә җиләкләрен сатып бетереп, кайтып та киткән иде инде.

Бирердә дә Мари Иле Республикасыннан килүчеләр күп иде. Әңгәмәдәшләрем арасында Казан янындагы бистәләрдән, Тәтеш, Биектау, Лаеш районнарыннан килүчеләр дә бар. Кемдер үз товарын алып килсә, кемдер бары тик сата гына.

Галимовлар гаиләсе Казанның Мирный бистәсеннән килгән булып чыкты. Үз теплицаларында кыяр һәм помидор үстерәләр.

– Элек без Җиңү проспектында сата идек. Хәзер анда халык йөрми башлады, сату бетте диярлек. Шуңа күрә бирергә күчтек. Ә каенанам электән үк шушында сата. Монда чыгымнар күбрәк, әлбәттә. Майдан алып октябрьгә кадәр урын өчен 12 мең сум түләп куябыз. Моңа көн саен тагын 400 сум өстәлә. Ләкин мин иялэштем инде, бирердә халык та күп, ошый да. Иртән 7дә киләбез дә көндезге 2дә кайтып китәбез. Гадәттә барысын да алып бетерәләр, – диде Альбина.

Аның әйтүенчә, урын өчен бәяләр быел сизелерлек арткан.

– Алыпсатарлар 700–800 сум сорый. Ә безгә, үз яшелчәләребезне үстереп саткан өчен, 400 сум түләргә кушалар. Дөрес әйбер түгел инде бу, – диде ул.

Шулай да аралашкан кешеләрнең күпчелеге базарга чыгып сатуның файдасы барлыгын әйтте. Иң зур табышны сезонында җиләкчеләр ала, помидор-кыяр, яшел тәмләткечләр сатучылар да алардан калышмый. Күләмнәрен әйтеп сөйләшмәсәләр дә, акмаса да тамып торуның хәерле икәнен аңларга була.

Иртә торсаң отасың

Базарда сату итүчеләр ике төркемгә бүленә. Кемнәрдер ара-тирә генә чыгып, аз гына товарларын сатып кереп китсә, кайсыларыдыр әлеге эшне кәсеп иткән. Андыйлар урын өчен бер елга алдан түләп куя, чөнки базарда урын алтынга тиң. Сатарга урын булмаганлыктан, кире борылып кайтып китүчеләр дә булгалый икән.

– Иртә торсаң отасың. Шуңа күрә без бик иртә киләбез. Сәгать 4тә торып, юлга 5тә кузгалабыз. 7гә инде монда булабыз, – ди Мәскәү базарындагы танышыбыз. – Әлегә сатарга урын бар. Узган ел бик авыр булды. Кеше өстендә кеше иде.

Сатучылар белән аралашкач, урын өчен түләү хакының урынга һәм товарның күләменә бәйле булуы аңлашылды. Мәсәлән, Мәскәү базарында беренче рәттә сату итү кыйммәтрәк, чөнки анда, беренчедән, сатып алучылар күбрәк йөри. Икенчедән, сату да яхшырак, тизрәк бара. Әчтәрәк, икенче рәттә сатучылар урын өчен 500 сумнан башлап түли. Өлкән апа-абыйларга бөтенләй бушлай. Кайбер көннәрне яшьрәкләргә дә бәхет елмаерга мөмкин икән: акчаны көн саен җыймаулары да бар.

– Мин сирәк чыгам базарга, – ди үз бакчасында кыяр үстерүче Галим Әбраров. – Күп булгач, үземнән артканын сатам инде. Ул кадәрне нишләтеп бетерим? Яшь вакытта бер районда агроном булып эшләгән идем. Шуңа күрә бакчада эшләүнең рәтен дә, рәхәтен дә беләм. Кыяр сатып, күп акча эшләп булмый, билгеле. Кеше янында булгач, үзе бер күңелле, дип йөрим.

«Элита»лы беренче рәт дигәннәрендә түләү, чыннан да, аерыла. Бирердә урын өчен көн саен 1000–1300 сум түлиләр. Моңа көн саен 50 сум лаборатория чыгымнары да өстәлә.

Үзәк базарда исә урын өчен түләү башлыча нәрсә һәм күпме күләмдә сатуга бәйле дип аңладык. Мәсәлән, сезон булганга күрә, җиләкчеләр күбрәк түли. Җиләк һәм помидор саткан апа 800 сум бирәм, дисә, яшел тәмләткечләр тәкъдим итүчеләр 300 сум түли икән.

– Урын белән проблемалар килеп чыгарга мөмкин. Сатучылар күп, ә урын аз. Яңа гына килеп сатарга теләүчеләргә авыррак шул инде. Шуңа күрә без урынны сатып алабыз. Ягъни бер елга 10 мең сум түләп куябыз. Һәм моңа өстәп, һәр килгән саен тагын 400–700 сумга кадәр түлибез. Күпме товар белән киләсең инде, – диде Мари Иленнән килеп, яшелчәләр, яшел тәмләткечләр, үләннәр сатучы Светлана Петрова. – Без көн саен киләбез. Теплицабыз бар. Әни дә сата монда. Ул җиләк өчен кыйммәтрәк түли.

Әбиләргә штраф?

Узган атнада матбугат чараларында Чаллыда тиеш булмаган урыннарда сату итүче әбиләргә штраф салачаклары турында хәбәр чыккан иде. Шундый мәйданнарның берсе шәһәрнең «Фонтан» сәүдә комплексы янында оешкан икән. Җәмәгать тәртибен саклау буенча идарә башлыгы Мөдәррис Миңнегалиев сүзләре буенча, Чаллыда бакчаларда үскән авыл хуҗалыгы продукциясен сата торган 28 урын бар.

– «Фонтан» комплексы янындагы мәйданчык ул исемлеккә керми, – ди ул. – Ләкин без анда әбиләргә штраф салырбыз дип әйтмим. Без алыпсатарларны күзәтәчәкбез. Тик кисәтәм: тиеш булмаган урында сату иткән өчен административ җаваплылыкка тартуда яшь киртә түгел.

Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсенең дәүләт ветеринар тикшерүе бүлеге җитәкчесе Идрис Гатин әйтүенчә, әлегә республикабызның бер генә шәһәрендә дә тиеш булмаган урыннарда сату итүче кешеләргә штраф салганнары юк.

– Без бары тик профилактика максатыннан гына кисәтү ясый алабыз, – диде ул. – Безнең инспекторларның беркетмә язарга рөхсәте юк. Билгеле, җәйге челләдә ит, сөт продуктлары саткан кешеләрнең документларын тикшерәбез, кирәк дип тапсак, кисәтү дә ясала. Ләкин үзеннән арткан яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәк, кайнатмалар саткан өлкән яшьтәге кешеләргә штраф салу дигән нәрсә юк.

Белгеч аңлатуынча, зур шәһәрләрдәге базарларда ветеринар-санитар лабораторияләр эшли. Сатучылар анда көн саен анализ бирергә тиеш. Сату мәйданнарына килгәндә, республика Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсеннән алынган мәгълүматлар буенча, алар 17 сату ноктасын контрольдә тота. «Ләкин без яшелчәләрне түгел, ә ит ризыкларын тикшерәбез», – дип аңлаттылар идарәдә.

Базар бәяләре

Ташкабак	100 сум
Кара җиләк	750 сум
Бөтнекнең бер бәйләме	50 сум
Помидор	150–350 сум
Бакча җиләгенең бер килограммы	200–250 сум
Бер стакан каен җиләге	300 сум

ҖЫЙДЫМ ҖИЛӘК

Николай Михайлов

«Мамадыш районының Уразбахты авылы халкы иң беренчеләрдән булып җиләк сата», – ди Әлфия Миңнеханова.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Мамадыш җиләкчеләре

Мамадыш районының Түбән Яке авылында туып үскән, хәзер шәһәрдә яшәүче Гөлсәрия ханым 17 ел инде бары тик каен җиләге генә җыя икән. Җиләккә иртәнге алтыдан калмый чыгып китәләр. Ел саен йөри торган үз урыннары бар. Җиләкле урынга эләксәләр, бер утырган җирдән бер майонез чиләген тутырып алалар. Җиләк әз булса, кенозын йөреп җыярга кирәк, ди.

– Җир җиләген җыя да алмыйм. Каеннныкын яратам, аны җыярга да рәхәт, – ди ул. – Җиләккә урманга йөрибез. Көндезге икеләргә кадәр ике кешегә бер 10 литрлы чиләк тутырып кайтабыз. Башта үзебез өчен туңдырып куябыз. Рәхәтләнеп ашыйбыз. Аннары сата башлыйбыз. Узган ел җиләк әз булгач, 10 көн генә саттык. Гадәттә, каен җиләген бер ай буе сатабыз. Акча күзгә күренеп керә. Үзегез исәпләп карагыз. Бер литрлы чиләк өчен узган ел 500 сум сорадык. Бер көнгә 10 чиләк сатарга була. 30 көнгә 150 мең сум кесәдә дигән сүз. Файда бит инде ул. Әле быел бәя дә арты. Башта 1 литрын 1 меңгә саттык, хәзер 800 сум инде.

Гөлсәрия ханым гаиләсе җиләкне «Сайкичү» дип аталган урынга (халык телендә аны "Зеленая стоянка" дип тә йөртәләр) алып барып сата. Ә менә Уразбахты авылындагылар юл буена гына чыга икән. Биредә халык бөтенләй башка. Алар, күрше-тирә авылларны уздырып, җиләкне беренчеләрдән булып сатарга ашыга. Гадәтләре шундый.

– Безнең әби, аягың тыпырдамаса, авызың шапылдамас, ди торган иде. Якеләрдән күреп тотындык без. Ул чакта әле җиләкне үзебез өчен җыя идек. Кеше саткач, без дә сатып карыйсы иттек, – ди Фәнис Юнысов. – Хәзер инде җиләк белән шактый акча эшлибез. Ничек җыясың, шулай сатасың. Гадәттә бер кеше көнгә 6 литр каен җиләге җыя. Җир җиләген 15–20 литр да җыеп була.

ТАТАРСТАНДА ҖИЛӘКЛЕ 5 УРЫН:

- **Мамадыш районының Дегетле авылы янәшәсендә;**
- **Балык Бистәсенең Олы Елга авылы янында;**
- **Арча районының Штерә авылы буенда;**
- **Биектау районының Озерный авылы буенда;**
- **Лаеш районының Чирпы авылы янәшәсендә.**



Түбән Тәкәнеш авылында яшәүче Әминә Ганиева каен җиләге үсә торган күп урыннарны белә. Яшәгән җирендә көндәшләре юк икән. Рәхәтләнеп җыям, ди.

– Ачык урыннарда җиләк пешкән инде. Карап кайттым мин. Әле миңа дигән җиләкләр тагын бер атнадан пешәчәк. Җәй – безнең өчен акча эшләү вакыты. Йокламасаң, эш уңа. Кызым да, улым да җиләк җыярга ярата. Узган ел кызым белән икебезгә бишәр литрлы 25 чиләк җир җиләге җыйдык. Ул чакта бәясе дә арзан иде әле. Чиләген 500 сумга саттык. Быел биш литрлы чиләктә җиләк 1500 сум тора.

Акчаның артыгы юк, ди ул. Сарай төзиләр икән. Җиләк акчасы шунда тотылачак. Шунысы бар: Әминә апа җиләкне элеккеге төсле юл буена чыгып сатмый хәзер. «Ватсап»та «авыл төркеме» бар, җиләкләрне фотога төшереп кенә җибәрә, шундук алалар.

Сату өчен түгел

Арчада яшәүче Сәгыйдә Габдрахманова инде берничә көн җиләккә йөри.

– Бездә «алмагач бакчасы» бар. Бөтен кеше шунда җиләк җыя. Ул бик зур. Һәркемгә урын җитә. Сатарга җыймагач, бер-береңнән көнләшү, узышып җыю юк. Әле менә бүген сарык бәрәне кадәр куян күрдем. Шушы яшемә җитеп, якыннан күргәнем юк иде. Ул куяннар шулкадәр эре икән, кешедән дә курыкмыйлар, – ди ул. – Мин ул бакчага җиләк дип кенә төшмим. Үләннәр дә җыям. Җиләкне бик сорасалар да сатмыйм. Балаларым, оныкларым өчен дип җыям. Иң элек кайтуга, каен җиләген сөт белән бутап, оныкларга коктейль ясап эчерәм. Аның бит витамины күп. Әгәр кеше бер стакан җиләк ашаса, ел буена җитәрлек витамин туплый.

Сәгыйдә апа әйтүенчә, быел җиләкне эзләп табасы. Кеше сүзенә ышанып, күрше авылга да барган булганнар. Әмма җиләк таба алмагач, кире үзләре җыя торган урынга әйләнеп кайтканнар.

Яшел Үзән районының Күгеш авылында да җиләк басуы бар икән. Печәнен чапкач, җиләк кыры ачылып кала, ди декрет ялындагы хезмәттәшебез Эльвира Вәлиева.

– Өч-дүрт ел инде каен җиләген шушы басудан җыябыз. Бөтен күрше авыл халкы безгә килә. Быел өч көн җиләккә бардык. Көненә 10–11 литр җыйдык. Кызганыч, басуыбызны сукалап киттеләр. Өч сәгатьтә җыябыз икән. Без җиләкне суыткычка изеп куябыз. Кыш буе рәхәтләнеп ашыйбыз. Кулдагы сәгать адымнарны санаган. Басуда биш мең адым йөрелгән, – ди Эльвира.

Җиләкче киңәшләре

ҖЫЮ СЕРЕ

✓Безнең якларда бер кеше үзе белгән урынны башкаларга сиздерми. Моның өчен иртәнге 4тә торып, болынга чыгып китә.
✓Җыеп утырган урынга башка кеше килә икән, күренмәскә тырышырга кирәк. Моның өчен үлән төсендәрәк кием кию хәерле. Башка ак яулык япмаска, кеше күрүе бар.
✓Шар ярып, кычкырып сөйләшү, хәтта адашкач, бер-береңә тавыш бирү дә начар гадәт булып санала.
✓Җиләккә барганда, каршыга кеше очрамау хәерле. «Юллыгы» начар булырга мөмкин. Безнең авылда каршыңа Люция апа Мусина очраса, чиләк тула. Буш чиләкле кеше күрсәң, кире борылып кереп торасы. Гадәттә, өй эчендә яхшы «юллыклы» кешене капкадан чыгарып, каршыга «очраталар».
✓Арттан кеше килсә, юлны бутыйлар.
✓«Оя»лыгың янына кеше килеп чыкса, үлән арасына кереп яталар.
✓Җиләкне беренче өзгәндә, бисмилланы әйтергә, уч тутыргач кына чиләккә салырга. Бу эшне кулы җиңел кеше эшләсә, чиләкләр тулачак.
✓Чиләк тулмыйча, җиләк ашамаска.
✓Җиләк «күчеп йөри». Бер елны булган урында икенче елны булмаска да мөмкин.
✓Өйгә кайтам, җиләк юк икән, дисәң, «оя»сына чыгасың.
✓Машина белән барсаң, аны җиләк җыю урыныннан бик еракта калдырырга кирәк.

САТУ СЕРЕ

✓Чиләкнең аскы ягына эресен, уртага вагын, өстенә кабат эрерәген салып җыярга киңәш ителә. Бушатканда матур күренәчәк.
✓Басылган чиләкне өстенә марля куеп кабартыгыз.
✓Җиләкне сыдырып кына җыйган кеше чиләк белән сату ягын карый. Бәясе дә арта, чүпле икәне дә сизелми.
✓Каен җиләген зур чиләккә җыймыйлар. Аны майонездан бушаган чиләк белән сату кулай.
✓Быел бер майонез чиләгенә 990–1000 данә җиләк сыя.
✓Җир җиләген зур чиләккә җыю отышлы.
✓10 литрлы чиләктәге җир җиләгеннән ике биш литрлы, бер майонез җиләге чыгарып була.
✓5 литрлы җир җиләгеннән 3 литр кайнатма чыга.

Бәясе:
→майонез чиләгендә каен җиләге – 700–1000 сум;
→5 литрлы чиләктә җир җиләге – 1500 сум;
→майонез чиләгендә җир җиләге – 400–500 сум.

Ярамый:
→бәяне төшерү;
→кеше килешкән сатып алучыны үзеңә тартып алу.

Ашаган белми, җыйган белә

Лилия Хаҗиева Казанда яши. Узган ел 20 көн рәттән каен җиләге җыйган. Быел әле ике генә көн барса да, 36 литр җиләк саткан инде.

– Мин күп еллар заказга җиләк җыям. Көтеп торучыларым бар. Җиләк җыярга бар кешенең дә сабырлыгы җитми шул. Без генә ул кечкенәдән эш белән үстек. Бик яратып җиләк җыя идек. Шуңа да мин бер авырсынмыйча рәхәтләнеп җыям. Сатып алучыларым бик рәхмәтле, – ди ул.

Лилия җиләк урынын белгертергә теләми. Казан янәшәсендәге бер районда, дип сүзне кыска тота. Ел да шул урынга бара икән. Кеше ияртеп йөрергә яратмый. Ялгыз тизрәк җыела, ди.

– Былтыр җиләк сезонын 8 июньдә ачкан идем. Быел соңга калынды. Җиләк күп түгел, әмма эре. Акчаның беркайчан артыгы юк, дим мин. Җиләк җыеп сату өстәмә эш кебек. Мин бит ике көн эшләп, ике көн ял итәм. Шул ялымда җиләккә йөрим. Аласы кеше бәясенә карамый ул. Минем унар литр сорап җыйдыручыларым бар. Кышка витамин туплап куялар, – ди Лилия. – Җиләк җыеп акча эшләү оят эш түгел. Аны бит әле күпләр булдыра алмый. Эссе көннәр була. Урман эчендә черки талый. Кыяк арасында җыйсаң, куллар киселә. Йөри-йөри гәүдәләр арый, билләр бөгелми башлый, аяк-куллар сызлый – саный китсәң, күп инде. Әмма мин бу эшне яратам. Ялгыз калгач, күңелемә рәхәт. Ял итәм. Табигатьтә хозурланып, чиләк тулганны сизмим дә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

15 июльдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Сәрия МИФТАХОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Беренче катлар ник буш?

«Салават Күпере» торак комплексында биек-биек йортларны бик күп салдылар. Тик аларның беренче катлары буш тора. Аларны арендага алып, ничек тә булса файдаланып булмый микән? Дәүләт торак фондының планнары нинди икән? Халыкка эш урыны булыр иде.

Әлфия КАРТАШОВА

Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының матбугат үзәге:

– «Салават Күпере» торак комплексындагы йортларның беренче катында торак булмаган биналар урнашкан. Алар арендага бирелми, ә электрон аукцион аша сатыла. Акрынлап үзләренең яңа хуҗаларын табалар. Чыннан да, микрорайонда йортлар күп салына. Быел гына анда 9 күпкатлы йорт тапшырдык. Тагын 3034 фатирлы 11 йортны кулланылышка тапшырасы бар. Алар инде төзелеп беткән.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Зиратны агачлардан чистартырлармы?

Иртә язда ук зираттагы агачларны кистеләр, тик бүгенгә кадәр аларны чистартып, алып чыгып бетерә алмыйлар. Агачлар шул килеш каберләр арасында ята бирә. Аларны чистартачаклармы икән? Әллә шул килеш череп беткәнен көтәләрме?

Гаҗилә ӘЮПОВА.
Әгерҗе

Рафаэль Ниязов, Әгерҗе шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе:

– Чыннан да, Иске мөселман зиратында агачлар киселде. Бу эшләр халыктан җыелган үзара салым акчасына башкарылды һәм бары тик агачларны кисү генә каралган иде. Икенчедән, аларны чыгарып та булмас иде, чөнки кайберләре бик зур. Киселгән агачларны, көзен өмә ясап, яндырачакбыз. Аларны зиратта калдырмаячакбыз.

Базар булырмы?

«Салават Күпере» торак комплексына зур булмаган азык-төлек базары кирәк иде. Ярминкәсе дә шунда булыр иде. «Радужный»дагы ярминкә урыны безнең өчен бик уңышлы түгел. Шәһәр җитәкчелеге бу турыда ни уйлый икән?

Әлфия КАРТАШОВА

Казан шәһәре мэриясенең матбугат хезмәте:

– Базарларны оештыру муниципалитет эшчәнлегенә керми. Алар шәхси предприятие булып тора. Мондый проектны тормышка ашырырга әзер инвестор барлыкка килгән очракта, Казан башкарма комитеты үз вәкаләте кысасында ярдәм күрсәтергә әзер. Сүз уңаеннан, «Залесный» торак массивында, «Салават Күпере, «Залесный сити» торак комплексларында, «Тасма» микрорайонында яшәүчеләргә уңайлы булсын өчен, ярминкәләр Осиново бистәсендәге «Радужный» сәүдә үзәге каршындагы мәйданда һәм «Яңа Тура» технополисында уза.

Бурычларны каян карап була?

Гаиләбез белән чит илгә ял итәргә барырга җыенабыз. Бурычларыбыз барлыгын-юклыгын каян белергә була икән?

Гөлнур ИСЛАМОВА.
Арча районы

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан буенча идарәсенең матбугат хезмәте:

– Чит илгә чыгар алдыннан бурычларны Салым федераль хезмәте, Таможня федераль хезмәте сайтларыннан яки ФССП сервисы аша тикшереп карарга мөмкин. Шулай ук күптән түгел генә Дәүләт хезмәтләре порталында яңа сервис барлыкка килде. Монда да бурычлары булган кешеләр илдән чыга алмаучылар исемлегенә эләгүләрен тиз арада белә ала. Алар шәхси кабинетның төп битендә күренәчәк. Тулырак мәгълүмат исә «Ход исполнительного производства» дигән башка сервиста урнаштырылачак. 30 мең сумнан артык бурычы булган кешеләргә, ә аерым категорияләр буенча, мәсәлән, алимент яки мораль зыян өчен, 10 мең сумнан артык әҗәте булган кешеләргә илдән чыгу чикләнергә мөмкин. Әгәр бурыч ике ай эчендә түләнмәгән икән, 10 мең сумнан артык бурычы булган кешегә приставлар илдән чыгуны чикли ала.

Яфраклар нигә саргая?

Быел зур юл буйларындагы агачларның яфраклары саргая. Барысы да түгел. Юлга якын булганнары. Әлеге хәл һава торышына гына бәйле түгелдер дип уйлыйбыз. Яфраклар күптән саргайды инде һәм бу хәл республиканың күпчелек районнарына хас. Әлеге күренешнең сәбәпләрен беләсебез килә. Белгечләр нәрсә уйлый икән?

Илнур ГАБДРАХМАНОВ.
Әлмәт районы

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының матбугат үзәге:

– Бу реагентлар нәтиҗәсе булырга мөмкин. Аларның көзен, кышын һәм язын агач сабакларына эләккән булуы бар. Сабаклар зарарлангач, бөреләр дә авыру була. Шуңа күрә агачлардагы яфраклар бик иртә саргая. Бу аеруча зур юл яннарындагы агачларга хас күренеш.

Наил Назаров, эколог:

– Юл буйларына утыртылган агачларның төп функциясе – юлдан үтүче машиналардан чыккан ягулык газларын һәм тузанны фильтрлау. Яфрак өслеге аша бу газларның күбесе үсемлек организмына эләгә һәм матдәләр алмашы циклында катнаша. Шул рәвешле үсемлекләр (иң беренче чиратта агачлар) һаваны чистарталар. Ләкин үсемлек организмына эләккән зарарлы матдәләр яфрак пластиналарында һәм агач кайрысында тупланып бара. Һәр төр агач яфрагының бу матдәләрне туплау мөмкинлеге чикләнү сәбәпле, яфраклар я иртәрәк саргаерга (бу дехромация дип атала), яисә корырга мөмкин. Өстәвенә мондый зарарлы газларны туплаган яфраклар корып җиргә коелгач, бу матдәләр туфракка сеңә һәм агачлар икенче тапкыр зыян күрәләр.

Шуңа күрә юл буе агачларының ылысяфракларының саргаюында искиткеч нәрсә юк. Әлбәттә, монда нигә шундый иртә саргаю күзәтелә дигән сорау туа. Бу, минемчә, быелгы язның чагыштырмача салкын килүе белән аңлатыла. Агач яфраклары үзләренең фильтрлау функциясен яхшы үтәү мөмкинлеге һава шартларының оптималь булуына бәйле. Иң беренче чиратта, эффектив температуралар суммасына бәйле. Әгәр үсемлек җитәрлек кояш нуры һәм җылылык алмый икән, әле кыраулар да булып торса, ул үзенең физиологик үсеш тизлегеннән тайпылып җитешә, чирли башлый. Бу очракта күп кенә экологик функцияләр дә үтәлми.

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

Фикер

МӘҢГЕЛЕК ЯРА

1949 елның 25 июнендә Апас урта мәктәбенең 10 нчы сыйныфында соңгы имтиханны бирдем. Шул көнне авылыбызга район партия комитетының беренче сәркатибе Зәки Фәйзуллин, район советы башкарма комитеты рәисе Бари Мифтахов, район комсомол комитетының беренче сәркатибе Харис Зәһретдинов һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре килде. Авыл клубында утырыш үткәреп, безнең гаиләне – әтием белән әниемне һәм аларның биш баласын Себергә сөргенгә җибәрергә карар кабул иттеләр. Әтиемне клубтан алып чыккач, хәтта 3,5 һәм 8 яшьлек сеңелләремне дә милиционерлар аның янына якын җибәрмәделәр. Аны алып киткәндә без елашып калдык. Ул көн күңелебездә мәңге төзәлмәслек яра булып торды. Өч көннән соң машина белән бөтенебезне дә алып киттеләр. 1955 елның апрелендә, алты ел сөргендә булганнан соң, безгә Татарстанга кайтырга рөхсәт бирделәр. Әтием һәм без – балаларының исеме сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабына кертелде. Зур теләгем бар: ул караңгы еллардагы гаделсезлекләр, вәхшилекләр, күз яшьләре беркайчан да кабатланмасын иде.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ

Җиңүче билгеле!

«ВТ» БҮЛӘГЕН ОТКАН ӘНИСӘ ХАНЫМ:

«Безгә эләгер димәгән идем»

Тагын бер тугры дустыбызны сөендердек. Июль ае язылучылары арасында уйнаткан бүләгебез – тандырны Зәй районының Дүрт Мунча авылында яшәүче Хәсәншиннар гаиләсе отты. Газетаны гаилә башлыгы Рәмис абый исеменә яздырсалар да, квитанцияне уенда катнашу өчен хатыны Әнисә ханым җибәргән.

«Узган ел мини-тракторга да өметләнгән идек, әмма анысы безгә чыкмады. Мин бит бүләк өчен генә укымыйм сезне. Гомерем буе, бер хәреф калдырмыйча, «Социалистик Татарстан» чагыннан бирле укып барам», – ди Әнисә Хәсәншина.

Газетаны яратуы, анда эшләүчеләрне хөрмәт итүе әллә каян сизелеп тора. «ВТ»ны һәр гаилә укырлык газета дип атады. Үзе дә заманнан калышмый, интернет белән дә дус. Шулай булса да, газетаның өйгә килүен дүрт күз белән көтә икән.

– Башта язмаларны сайлап кереп укыйм. Аннары кәгазь вариантын көтәм. Күпме генә укысам да туймыйм. Бер хәрефен төшереп калдырмыйм. Ирем дә газетаны бик ярата. Бүләк отканны шалтыратып әйткәч, бик сөендек. Безгә эләгер димәгән идем. Әле моңа кадәр бер әйбер дә откан юк иде. Барысын да үзебез эшләп таба идек, – ди ул.

Әнисә ападан авыллары хакында да сораштык.

– Бик тату яшибез. Авылда 140лап хуҗалык бар. Өлкәннәребез күп. Яшьләр дә бар. Күңел шунысына сөенә: авылыбыз яши әле. Элеккеге төсле колхозлар булмаса да, агрофирмабыз гөрләп эшли. Халык күпләп мал тота. Үзебез дә сыерлар асрыйбыз, үгезләребез бар. Җәйге чорда күп итеп кош-корт алабыз, – диде ул.

Рәмис абый гомере буе механизатор булып эшли. Әнисә апа исә мәктәптә җыештыручы булган, пенсиядә. Уларының – үз тормышы, хатыны белән ике бала үстерәләр икән.

– Балалар бик тә шашлык ярата. Бу тандырның безгә эләгүенә әле дә ышанып бетеп булмый әле. Алла боерса, рәхәтләнеп кулланырбыз инде. Караган саен сезне искә алырбыз. Күп еллар газетаны алдырып барганыбыз өчен нинди зур бүләк булды бит, – ди Әнисә апа. – Редакция коллективына зур рәхмәт! Укучыларны хөрмәт итеп, төрле бәйгеләр уздырып торганыгызга күңел сөенә. Башкалар нидер отса да, шатланабыз без. Иң мөһиме – игътибар бит. Минә шунысы өчен аерым рәхмәт. Киләчәктә язылучыларыгыз артып кына торсын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

11 июль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК-2» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.30 Новости Татарстана 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
23.50 «Семь дней +». Р.Салихов 12+
00.15 «Каравай» 6+
00.40 «Семь дней +». Ф.Кагиров 12+
01.05 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Җырларымда син генә». Рафил Җәлалиев һәм Эльмира Гыйльфанова концерты 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Әлфия Авзалова турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Фикрәт Табиев турында телеочерк 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Елена Панова в многосерийном фильме «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 «РОМАНОВЫ. ВЕНЦЕНОСНАЯ СЕМЬЯ» 0+
02.40 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ. СУДЬБА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 16.50, 19.55 Новости
06.05, 16.30, 17.25, 21.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 00.45 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
09.35 Смешанные единоборства. UFC. Лучшие бои Конора Макгрегора 16+
10.35 Кубок PARI Премьер. Итоги 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40, 02.55 Спец. репортаж 12+
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Женщины. Трамплин 1 м. Прямая трансляция из Пензы
16.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Мужчины. Синхронные прыжки. Трамплин 3 м. Прямая трансляция из Пензы
17.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Женщины. Синхронные прыжки. Вышка. Прямая трансляция из Пензы
18.20 Матч! Парад 16+
18.55 «Громко» Прямой эфир
20.00 Бильярд. «BetBoom Кубок Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
21.50 Футбол. Чемпионат Европы-2022. Женщины. Англия – Норвегия. Прямая трансляция из Великобритании
01.05 Мысли как Брюс Ли. «Будь водой». Док. фильм 12+
03.15 Новости 0+
03.20 «Где рождаются чемпионы. Михаил Алоян» 12+
03.50 «Третий тайм» 12+
04.15 Прыжки в воду. Чемпионат России. Трансляция из Пензы 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова» (S) 12+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 Екатерина Климова в детективном сериале «ОПЕКУН» (S) 16+
21.40 Премьера. Сергей Астахов/ «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
01.55 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Ни тебе ни мне» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ОПЕКУН» 16+
19.00 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
22.45 «Порча» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.20 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 1-я и 2-я серии 16+
03.00 «Тест на отцовство» 16+
04.40 «Давай разведёмся!» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.30, 00.20 «ДОБРОЕ УТРО» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.25, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
14.00 Военные новости. 16+
14.05 «ЗОЛОТОЙ КАПКАН» 16+
18.50 «Битва ставок». Документальный сериал. «Операция «Барбаросса» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Советский призрак над странами НАТО» 12+
20.30 Новости дня 16+
22.55 «РАССЛЕДОВАНИЕ» 12+
01.50 «МЫ, ДВОЕ МУЖЧИН» 12+
03.15 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+
04.40 «Брестская крепость». Док. фильм 12+

12 июль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК-2» 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ» 12+
11.00 «Фолиант» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Без химии». Док. фильм 12+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». У истоков жизни. В.С.Груздев 12+
00.40 «Каравай». Мастер этно-художественного кадра 6+
01.05 «Уроки истории» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Бәйрәмнең дә бәйрәме» 6+
19.35, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Рәшит Зәкиев турында телеочерк 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 «Цареубийство. Следствие длиною в век». Фильм первый 12+
01.05 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ. СУДЬБА» 12+
02.45 «ПО ГОРЯЧИМ СЛЕДАМ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.35, 14.55, 16.50, 19.55 Новости
06.05, 16.25, 17.35, 18.20, 21.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 00.45 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
09.35, 01.05 «ЦЕПЬ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40, 02.55 Спец. репортаж 12+
13.00, 15.00 «ПОБЕГ» 16+
15.55 Матч! Парад 16+
16.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Мужчины. Трамплин 1 м. Прямая трансляция из Пензы
17.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Женщины. Синхронные прыжки. Трамплин 3 м. Прямая трансляция из Пензы
18.55 Прыжки в воду. Чемпионат России. Мужчины. Синхронные прыжки. Вышка. Прямая трансляция из Пензы
19.25 «РПЛ. Лицом к лицу» 12+
20.00 Смешанные единоборства. UFC. Рафаэль Дос Аньос против Рафаэля Физиева. Трансляция из США 16+
21.50 Футбол. Чемпионат Европы-2022. Женщины. Германия – Испания. Прямая трансляция из Великобритании
03.15 Новости 0+
03.20 «Где рождаются чемпионы. Алан Хугаев» 12+
03.50 «Зенит». День за днём» 12+
04.15 Прыжки в воду. Чемпионат России. Трансляция из Пензы 0+
05.05 «Спорт высоких технологий». Док. фильм 12+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова» (S) 12+
09.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 «ОПЕКУН» (S) 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.55 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Свадебная порча» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ДОМ НА КРАЮ ЛЕСА» 16+
19.00 «О ЧЁМ НЕ РАССКАЖЕТ РЕКА» 16+
22.40 «Порча» 16+
23.15 «Знахарка» 16+
23.45 «Верну любимого» 16+
00.15 «Понять. Простить» 16+
01.15 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 3-я и 4-я серии 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ЗОЛОТОЙ КАПКАН» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.30, 00.35 «ОТЦЫ И ДЕДЫ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 18.15 «Спец. репортаж» 16+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «ЗОЛОТОЙ КАПКАН» 16+
18.50 «Битва ставок». Док. сериал. «Крушение «Барбароссы» 16+
19.40 «Улика из прошлого». «1941. Почему минировали столицу: рассекреченные материалы» 16+
20.30 Новости дня 16+
22.55 «ДВОЙНОЙ ОБГОН» 16+
02.00 «ВСЕ ТО, О ЧЕМ МЫ ТАК ДОЛГО МЕЧТАЛИ» 18+
03.45 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ

11–17 ИЮЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Шактый ук киеренке атна көтә сезне. Байтак тир түгеп кенә җиңүләргә ирешеп булачак. Хәер, бу чордагы көч-куәтегез, кем әйтмешли, таулар күчерергә җитәчәк!

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Җитәкчегез күзенә артыгын чалынмыйча йөрү әйбәтрәк булыр. Сәбәпләре атна уртасында ук ачыкланыр. Үткенлегегез нәтиҗәсендә дошманнарыгызны көнләштерерлек уңышка ирешелер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Күтәренке хезмәт хакы яки бик әйбәт гонорар көтегез. Дүшәмбедән үк башланып киткән эшлекле очрашу-күрешүләр бераз алҗытыр. Ә менә мәхәббәт өлкәсендә – көтеп алынган үзгәрешләр...

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Атнаның беренче яртысында ниндидер бер яңалыкка өйрәнерсез, кешеләр белән бик күп аралашырсыз. Шулай итеп, көтмәгәндә генә үзегез өчен яңа бер дөнья ачкандай булырсыз. Кыскасы, эшләрегез гөрләп барыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Кешегә карап кабаланмагыз, үзегезгә ничек җайлы – шулай барыгыз. Барысын да җитди кабул итмәгез: эштә, үзара мөнәсәбәтләрдә «хулиганланып» та алыгыз. Җиңеллек биреп, иҗади мөмкинлекләрегезне ачачак бу.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Җәйге күңел күтәренкелеге эштәге бик катлаулы мәсьәләләрне тиз һәм җиңел хәл итүгә китерәчәк. Читтән ярдәмгә өметләнмәү хәерлерәк. Атна ахырында күңелле яңалыклар булачак.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Хезмәт урынында югарырак баскычка күтәрелү ихтималы зур. Ачылып китеп, бөтен серләрен сөйләп биргән бер танышыгыз тормыш мәгънәсе турында уйга салырга мөмкин.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бик табышлы бер эш табып бирерләр. Булдыра алмамдыр, дигән уйларны куып җибәрегез дә – алга! Ял көннәрендә бер дустыгызның чын мәгънәсендә тугры булуына инанырсыз.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Билгеле бер сәбәпләр эштә үзегезне аеруча кирәкле кешегә әйләндереп куяр. Өстәвенә әле атна уртасында яңа мөмкинлекләр ачардай хәлләр булып алыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Эшләрегезне генә түгел, йөз-кыяфәт, өс-башыгызны да тәртипкә салу теләге туар. Бу җәһәттән бер дустыгызның киңәше бик тә ярап торыр.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Тынгысызрак атна. Эштә киеренкелек, өйдә... Ләкин борчыласы юк: озакламый бу тынгысызлыкның шулай кирәк булганлыгын дәлилләрдәй әйбәт кенә җимешләре күренә башлар.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Сәяхәткә чыгу өчен менә дигән чор: маҗаралар, серле вакыйгалар көтә бугай сезне! Сөйкемле, мөлаем булуыгыз кытыршырак мәсьәләләрне җайлау-майлау мөмкинлеге бирер. Ял көннәрендә бик бәхетле мизгелләр кичерергә насыйп булыр.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлештәге чараларны үстерү һәм аларга булышлык итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры **Миңнегалиев** Роберт Хәмит улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Алимова** Нурдания Нәбиулла кызына, «П.В. Дементьев исемендәге агрофирма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Үби товарлыклы-сөтчелек фермасы машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Антипова** Ирина Михайловнага, «Авангард» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Ибраһимова** Нурдания Ризатдин кызына, «Битаман» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сыер савучысы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Сабирҗанова** Рәдисә Тәүфикъ кызына, «Хезмәт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Щербакова** Любовь Васильевнага, «Наратлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Яппарова** Дилүзә Әгләзетдин кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Зилант» боз сарае» укыту-спорт комплексы директоры **Зиндеев** Анатолий Николаевичка, «Кэмпо» көрәш буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары (Чаллы шәһәре) **Красноперова** Зөлфия Хәмзә кызына, «Р.Г. Нәҗметдинов исемендәге шахмат, шашка, го буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе директорының спорт-массакүләм эш буенча урынбасары **Сәйфетдинов** Нәркиз Әмин улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе **Закиров** Ильяс Гарәфетдин улына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесенең җирләрдән файдалану бүлеге башлыгы урынбасары **Мулина** Евгения Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Бөрбаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Габдрахманов** Альберт Габделфәрт улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БИТАРАФНЫ ЯРАТМЫЙ

Җир йөзендә яшәүче һәр өч кешенең берсе баш авыртудан интегә, ди белгечләр. Безнең өчен гадәти күренешкә әверелеп барган әлеге халәтнең берничә төрен аера алар. Киеренкелек аркасында баш авырту шулар арасында иң киң таралганы санала. Табиб-невролог Эльвира ДЕМУШКИНАдан баш авыртуның әлеге төре турында тәфсилләбрәк сөйләвен сорадык.

✓Киеренкелек аркасында баш авырту (головная боль перенапряжения) – замана чире, дисәм дә, арттыру булмас. Бүген ул, нигездә, 25–40 яшьлекләр арасында очрый. Бу очракта арка һәм баш мускулларының озак вакыт киеренке халәттә булуы аркасында авырта ул.

✓Авырту көчле түгел, бер көйгә туктаусыз борчып тора. Киеренкелектән баш авыртканда кеше башына авыр башлык яки кырышау киеп куйган кебек хис итә. Баш ике яктан да бер үк дәрәҗәдә авырта.

✓Киеренкелектән баш авыртуга, нигездә, эш урынында, бигрәк тә эш өстәле янында дөрес утырмау да сәбәпче була. Кирәксә-кирәкмәсә, көне буе телефонга багынып утыруыбыз да эзсез калмый. Телефонга текәлеп утырганда баш 35 градустан да ныграк иелсә, муенга 25 килограммлы йөк күтәргән кадәр көч килә. Көянтә белән туп-тулы ике чиләк су күтәреп тору белән бер бу. Муенга көч килгәч, баш та авырта, билгеле. Даими рәвештә стресс кичерү, күңел төшенкелегенә бирелү дә киеренкелектән баш авыртуга сәбәпче була ала.

✓Гәүдә төзелеше симметрияле булмаган кешеләр дә еш кына әлеге төр баш авыртудан интегә. Әйтик, кемнендер бер аягы яки кулы икенчесенә караганда озынрак булырга мөмкин. Андый очракта организмда кан дөрес йөрми башлый. Нәтиҗәдә баш мие дә аңа тиешенчә туена алмый. Бу исә, үз чиратында, баш авыртуга китерә. Уңайсыз аяк киеме киеп йөргән, яссытабанлылыктан интеккән кешеләр дә киеренкелектән баш авырту дигән күренеш белән яхшы таныш.

✓Киеренкелектән башы авырткан кешене мондый «өянәк»ләр, гомумән алганда, айга 20 көн чамасы борчый. Әмма вакытында чарасын күрмәсән, мондый төр баш авырту хроникка әверелергә дә мөмкин.

✓Мондый төр баш авырту вакытында базилик, канәфер, лаванда, лимон, мелисса, бөтнек исләре дә хәлне җиңеләйтәчәк. Гади генә күнегү дә хәлегезне җиңеләйтәчәк. Имән һәм урта бармаклар белән, әйләнмәле хәрәкәтләр ясап, чигәләрегезне, маңгаегызны, җилкә мускулларын уыгыз. Шуннан соң кан йөреше яхшыра, мускуллар йомшара. Әлеге массажны 10–15 тапкыр ясарга кирәк. Баш миендәге кан әйләнешен яхшырту өчен ясалган күнегүнең дә файдасы тими калмас (рәсемдә↓).

КИЕРЕНКЕЛЕКТӘН БАШ АВЫРТУНЫ КИСӘТҮ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

➔Һәрчак хәрәкәттә булыгыз. Көн дәвамында физик күнегүләр ясарга, саф һавада йөрергә ярты сәгать булса да вакыт табарга тырышыгыз. Бу очракта сезгә баш авыртуның бер төре дә куркыныч булмаячак.

➔Ашаган ризыкка да игътибар итү сорала. Баш авыртудан интеккән кешегә майлы ит, кызыл шәраб, каһвә, чәй, энергетик эчемлекләр белән мавыгырга ярамый. Составында глютен, сөт шикәре (лактоза), җиңел углеводлар булган ризыклардан да баш тарту хәерле.

➔Көненә ким дигәндә сигез сәгать йоклау, эш белән ялны чиратлаштыра белү дә киеренкелектән коткара, организмны шул авырулардан, шул исәптән баш авыртудан да саклый. Көне буе компьютер каршында утырып эшләгән яки гел бер төрле эш башкарган кешегә дә сәгать саен унбиш минут ял итеп алырга кирәк.

➔Баш авыртуы үз сәламәтлегенә битарафларны яратмый. Шуңа күрә авыртуга түзәргә ярамый. Баш авырту даими рәвештә борчый башлауга, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Киеренкелектән котылу өчен, елга бер тапкыр булса да, баш, муен тирәсенә массаж ясату хәерле.

Сорау – җавап

Күкрәк сөтеннән кайчан аерырга?

? Балама – 1,2 яшь. Балага бер яшь тулгач, күкрәк сөте акрынлап файдалы үзлекләрен югалта башлый, суга әйләнә, диләр. Бу, дөрестән дә, шулаймы икән? Аңлатып китегезче, зинһар.

Диләрә МИНҺАҖЕВА. Сарман

Сорауга балага күкрәк сөте имезү буенча консультант Маргарита МАРЬИНА җавап бирә:

– Бу фикер белән һич кенә дә килешмим. Күкрәк сөте файдалы үзлекләрен беркайчан да югалтмый. Киресенчә, сабыйны озаграк имезгән саен файдалырак, туклыклырак була бара ул. Мисал өчен, балага бер яшь тулганчы күкрәк сөтенең майлылык дәрәҗәсе 4,5 процент тәшкил итә. Өч яше тулганда инде ул 17 процентка (!) җитә.

Анага да, балага да уңайлы икән, күкрәк сөтен күпме имезсәң дә ярый. Күкрәк сөте, гадәттә, бер яшькә кадәр баланың төп ризыгы булып тора. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы вәкилләре баланы ике яшькә кадәр имезергә киңәш итә. Әмма үз тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: 1,5 яшьтә инде бала, гадәттә, күкрәк сөте белән хушлашырга әзер була.

Үзем сынадым

Кәбестә яфрагы коткарды

Соңгы елларда гел баш авыртудан тилмерәм. Нинди генә ысул кулланып карамадым. Бу арада кәбестә яфрагының файдасын күрә башладым әле. Аны кайнар су белән йомшартып алам да, бераз ваклап, башның авырткан урынына куеп торам. Ярты сәгать дигәндә баш авыртуы юкка чыга.

Рауза МАННАНОВА. Теләче

Үзе тәмле, үзе шифалы

Бакча җиләге өлгергән чак. С витаминына иң бай җимешләрнең берсе ул. Аның 100 граммында әлеге төр витаминның көнлек нормасы бар.

Бөер һәм сидек юллары авырулары белән интегүчеләргә җәй буе бакча җиләге ашарга киңәш итә табиблар, чөнки ул бәвел куу үзлегенә ия. Бөер авыруларыннан бакча җиләгенең җимешләре генә түгел, тамыры да файдалы. Аларны төнәтеп эчү бөерләрнең эшчәнлеген яхшыртып җибәрә.

✓**Эчәклекләр, сидек куыгы һәм бөерләр ялкынсынудан** көн саен ике-өч стакан бакча җиләге чәе эчәргә киңәш ителә. Аны әзерләү өчен ике аш кашыгы киптерелгән җиләкне бер стакан кайнар суга салып төнәтергә кирәк.

pixabay.com

✓Җиләкнең яфраклары исә **подаградан (организмда матдәләр алмашыну бозылу аркасында барлыкка килә торган тире һәм буын авыртуы)** булыша. Зур гына өем киптерелгән яки яңа өзелгән яфракларны ярты литр суда төнәтеп, өстен каплаган килеш 10 минут тирәсе ут өстендә кайнатып алырга. Ашар алдыннан 100 мл күләмендә эчәргә кирәк. Бу төнәтмәне суыткычта ике тәүлек буена сакларга мөмкин. Шушы ук эчемлек бөер авыруларыннан да файдалы.

✓**Ангинаны һәм тамак ялкынсынуларын** дәвалау өчен, термоска җиләкнең киптерелгән яфракларын һәм чәчәкләрен салып, өстенә бер стакан кайнар су өстәп, сәгать буе томалап торырга кирәк. Соңрак һәр ике-өч сәгать саен авызны, тамакны шушы төнәтмә белән чайкарга.

✓**Шешенүләрдән һәм югары кан басымыннан** җиләкнең киптерелгән яфракларын стаканга салып, чәй пешергән кебек пешереп эчү булыша. Тәм өчен бер кашык шикәр комы өстәсәгез дә була.

Бакча җиләгеннән яшәртүче битлек

●Берничә бакча җиләген төеп, барлыкка килгән ботканы биткә сыларга һәм 15–20 минут тотарга кирәк. Тирегез коры булса, бераз үсемлек мае да өстәгез.

●Ике аш кашыгы төелгән җиләкне бер чәй кашыгы крем һәм бер чәй кашыгы бал белән болгатырга. Бу катнашманы бит тиресе коры булган кешеләр маска рәвешендә куллана ала. Биткә сылап, ун минут тирәсе тотканнан соң, җылымса су белән юып алырга.

●Ике аш кашыгы төелгән җиләкне бер аш кашыгы эремчек белән яхшылап болгатырга. Биткә калын катлам итеп сылап, 15–20 минутка калдырырга, соңрак юып төшерергә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ҮЛӘНДӘ ИКӘН ХИКМӘТ

Дару үләннәрен җыючылар елдан-ел арта. Гаҗәпләнәсе юк: кеше сәламәтлекнең табигый чыганакларын эзли. Үләннәр табигатьнең иң кыйммәтле байлыкларыннан берсе булып тора һәм безгә әйбәт кәеф-рух бүләк итә.

Үләннәрне дөрес итеп җыю һәм әзерләү буенча бүгенгә ниләр мәгълүм? Бу хакта халык табибы, үләннәр белән дәвалаучы Фирая ЗАХАРОВАдан белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Фирая ханым, Беренче каналның «Доброе утро» тапшыруында үләннәрдән сихәтле мендәрләр ясау серләренә өйрәттегез. Безнең укучыларга да шул хакта сөйләп үтегез әле.

– Мендәрне теләсә нинди үләннән ясарга мөмкин. Иң мөһиме – исенең күңелегезгә хуш килүе һәм аллергия бирмәве. Үлән мендәрләре алҗуны бетерә, нерв системасын, йөрәкне тынычландыра, йокысызлыктан коткара, сулыш юлларын чистарта. Колмак күркәләре исе хәтта гырлауны да бетерүгә ярдәм итә. Тик мендәрне тулысынча хуш исле үләннәрдән генә ясау дөрес түгел. Ник дигәндә, көчле ис, борынны кытыклап, киресенчә тәэсир ясарга – йокыны качырырга мөмкин. Шуңа күрә мендәрне ике төрле: исле һәм иссез үләннәрдән ясыйлар. Әнис, колмак, бөтнек, сары һәм зәңгәр мәтрүшкә, юкә чәчәге кебек хуш исле үләннәрдән тыш, бераз гына салам, кыяк үлән (осока), кырлыган (иван-чәй) мамыгы өстәргә мөмкин. 20х20 үлчәмендәге мендәр ясау өчен ярты кило чамасы кипкән үлән кирәк. 7–10 көн шундый мендәрдә йоклаганнан соң берникадәр вакыт гадәтиенә күчәргә була. Үлән мендәре, сихәтен җуймыйча, бер елга җитә.

:: Ә үләннәрне, шул исәптән мендәр ясау өчен дә, кайчан җыю дөресрәк? Питраудан соң үләннәрнең шифасы бетә, дип сөйлиләр. Бу фикер белән килешәсезме?

– Юк, килешмим. Үләннәрне иртә яздан алып кара көзгә кадәр җыярга мөмкин. Аларның күбесе чәчәк аткач җыела. Шунысы да бар: республиканың төрле төбәкләрендә үсемлекләр бер үк вакытта чәчәк атмый. Әйтик, көньяк районнар белән төньяк районнарда аерма ике атнага җитә һәм кайчак аннан да артып китә. Кайбер районнарда яңгырлар күп булырга, кайберендә җәй буе чык та төшмәскә мөмкин. Монысы да үләннәр өлгерүгә нык тәэсир итә.

:: Шулай да үләннәр елның кайсы фасылларында бигрәк тә файдалы?

– Гомумән алганда, җәй айларында чәчәгендә һәм яфрагында, ягъни җирдән өске өлешендә файдасы күбрәк була. Ә язын һәм көзен – тамырларында. Шунысы да бар: кайбер үләннәр ир-атлар һәм хатын-кызларга төрлечә тәэсир итә. Мәсәлән, сары мәтрүшкәне һәм бөтнекне ир-атларга артык күп кулланырга ярамый.

:: Менә хәзер ниндиләрен җыеп куярга мөмкин?

– Чәчәк аткан барлык үләннәрне диярлек, шулай ук җиләк яфракларын, арасында үсә торган төк чәчәк (манжетка), тубылгы (таволга, лабазник – печән арасында үсә), юкә чәчәге, ромашка, кычыткан, меңьяфрак, канлы үлән, наратбаш (хвощ), кырлыган, эт тигәнәген (репешок), кандала үләне (донник), цикорийны. Юкә димәктән, чәчәге генә түгел, кайрысы да файдалы. Аның көле паразитларны чыгарырга ярдәм итә. Бер көнгә бер чәй кашыгы көлне су белән йотып куярга кирәк. Шул рәвешле берәр атна чамасы дәваланырга мөмкин. Ләкин башта табиб белән киңәшләшергә онытмагыз. Шулай ук үлән төнәтмәләрен ясап эчүгә, үләннәрне башкача куллануга да кагыла бу.

:: Киптерү, саклау буенча да киңәшегезне биреп үтсәгез иде.

– Иң яхшысы – үләннәрне чормада яки җилләтелә торган башка урында киптерү. Үги ана яфрагын, бака яфрагын берәмтекләп, кәгазьгә тезеп киптерүдән дә яхшысы юк. Бер-ике көннән икенче ягына әйләндереп куярга кирәк. Өсте-өстенә өйсәк, каралып китәчәк, начар кибәчәк. Мәтрүшкә, ромашкаларны бәйләмгә җыеп киптерергә була. Каен яфрагын исә мунча себеркесе кебек җыеп, элеп киптерәбез. Ә менә үлән тамырларын кояшта киптерү әйбәт. Саклауга килгәндә, тулысынча кипкән үләннәрне кәгазь капчыкларга, катыргы тартмаларга салып, нинди үлән икәнен, кайчан җыелуын язып, караңгырак урынга – шкаф тартмасына алып куябыз. Температурасы 20 градустан артмаган бүлмәдә саклау әйбәтрәк. Үләнне вакланган килеш кулланырга кирәк булса, кулланыр алдыннан гына ваклыйбыз.

Бакчачы почмагы

Сорауларга бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә

? Теплицада икенче төп кыяр корый инде. Сабагы астан агара. Кыярлары да күп үзенең...

Светлана БЕЙБЫТОВА. Казан

– Фузариос авыруы зарарлагандыр, күрәсең. Сабагының зарарланмаган өлешен җиргә күмеп, фитоспорин сиптереп карагыз. Яңа тамырлар чыгарыр, бәлки. Агарган урыннарына «зеленка» сөртергә мөмкин.

? Суган кыяклары шәмәхәләнә башлады. Ниндидер чирдер инде бу. Аларга ничегрәк хәл кертеп булыр икән?

Римма ГАРИПОВА. Чирмешән районы

– Гадәттә пероноспороз, ягъни ялган онсыл чык авыруы яшелчәне шулай зарарлый. Бу гөмбәчек җил, яңгыр, сипкән су белән тарала. Туфракта дым күп булып, һава температурасы 16 градустан түбәнрәк торганда да пәйда була. Башта кыяк очларында сары таплар барлыкка килә, шуннан соң ул шәмәхәләнә. Вакытында чарасын күрмәсәң, кыяклар шиңеп, юкка чыга. Мондый очракта, беренчедән, бик нык зарарланганнарын йолкып ташларга кирәк. Гөмбәчекнең башланган чорында 1 процентлы бордос эремәсе, «Оксихом» яки «Ридомил Голд» сиптерергә кирәк. Халык ысулын да кулланып карарга мөмкин. Түтәлләргә эремчек суы (1:10 нисбәтендә су кушып) сиптерергә була. Өстеннән көл бөрку дә файдалы. Әмма туфрагына да сибәргә кирәк. Ләкин киләсе елда бу урынга суган утыртырга ярамый. Көзен җирнең өске катламын алып ташлап, казып калдырырга кирәк булачак. Гомумән, суганнарны кояшлы урынга утыртырга һәм суны артык күп сипмәскә кирәк.

Аш-су

Сарымсак угыннан – тәмләткеч

Кирәк булачак: 0,5 литрлы банка өчен – 0,5 кг сарымсак угы, 1 аш кашыгы тоз, 1 аш кашыгы (түбәләмә итеп) шикәр комы, 50 грамм 9 процентлы серкә, 5 түгәрәк кара борыч, 1 дәфнә яфрагы.

Укларны юып, 5–10 см озынлыкта турыйбыз. Банкага дәфнә яфрагы, тоз, борыч, шикәр комы салабыз. Сарымсак угын тыгызлап тутырабыз. Өстенә кайнап торган су агызып, капкач белән каплыйбыз һәм 20 минут тотабыз.

Суны кәстрүлгә бушатып, яңадан кайнатып чыгарабыз. Серкә өстибез. Кайнап чыккач, тозлыкны банкага агызып, капкач белән борып ябабыз. Җылы әйбер белән каплап, суынгач, салкынча урынга алып куябыз.

Салатларга өстәп җибәрү өчен яки кайнар бәрәңге янына менә дигән тәмләткеч!

Белсәң, зыян итмәс

АНАНАС СУЫН ТҮКМӘ

Консервланган ананас яки персикның суын түгеп әрәм итмәгез. Аны төрле максатта кулланырга мөмкин.

➤Иң гади ысулы – газлы суга өстәп җибәрү. Бик тәмле эчемлек килеп чыгачак.

➤Сыекчадан маринад әзерләп, тавык итен шунда маринадларга мөмкин. Моның өчен тирән эчле зуррак савытка 60 мл ананас яки персик суы, 1 аш кашыгы үсемлек мае һәм 1 аш кашыгы серкә өстәргә кирәк. Итне 30 минут маринадта тоткач, пешерергә яки кыздырырга.

➤Дөге суына шушы сыекчаны өстәп җибәргән очракта, ризык бик тәмле була.

ОЕКТАН – ЙОМШАК МЕНДӘР

Тузган капрон оеклардан менә дигән мендәр эчлеге ясарга мөмкин. Үткен кайчы белән аркылыга токмачлап турыйбыз. Шуннан мендәр эченә тутырабыз. «Токмач»лары никадәр юкарак булса, мендәр шуның кадәр йомшаграк килеп чыгачак. Мондый мендәрне юу да бик уңайлы: гадәти кием кебек, кул белән генә юасы. Формасына да зыян килми һәм төерчекләнми дә.

ШПИНАТТАН – БИТЛЕК

Иртән торганда, күп кенә хатын-кызларның күз төпләре шешенке була. Бу очракта шпинат яфраклары («свежий» яки катырылган) ярдәмгә килергә мөмкин. Ә инде битлек ясау өчен согы кирәк булачак. 1 чәй кашыгы шпинат согына 10 мл күләмендә майлы А витамины эремәсе (аптекада сатыла), күз тирәсенә сөртә торган теләсә нинди крем (1 чәй кашыгы) өстәп болгатабыз. Катнашманы күз тирәсенә сылап, 20 минут тотабыз. Шуннан мамык дискын кайнаган салкын сөттә чылатып, битлекне сөртеп алабыз.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КАДЕРЛЕ ДӘ, ҖАВАПЛЫ ДА СӘФӘР

Үз гомерендә бер генә мәртәбә булса да хаҗга барып кайта алган мөселман – иң бәхетлеләрдәндер. Мөселманнар өчен бу сәфәр нинди әһәмияткә ия? Хаҗ кылуның нинди кагыйдәләре бар? Башка берәү өчен хаҗга бару ярыймы? Бу һәм башка сорауларга «Билал» мәчете имамы Җәлил хәзрәт ШӘВӘЛИЕВ ачыклык кертте.

:: Хаҗ кылу турында Коръәндә ни диелә? Хаҗ кылу кемгә фарыз? Хаҗ кылучы кешеләргә нинди таләпләр бар?

– Изге сәфәр турында: «Мөмкинлеге булган һәм ул юлны үтәргә хәленнән килгән кешеләргә ул йортка хаҗ кылуны Аллаһы бурычлы итте», – диелә Коръәндә. Димәк, мөмкинлек булганда, хаҗны кылу фарыз. Матди һәм физик җәе булган һәр мөселман гомерендә бер тапкыр зөлхиҗҗә аенда хаҗга барырга тиеш.

Шартлары димәктән, беренчедән, хаҗ кылучының мөселман булуы шарт. Ә инде биш вакыт намазын укып, ислам диненең бөтен йолаларын җиренә җиткереп үтәүчеләрдән икән – бу нур өстенә нур гына булыр. Физик яктан әзерлекле булуы да мөһим, чөнки хаҗ йоласын башкарганда байтак араны җәяүләп, ир-атларга исә хәтта яланаяк та үтәргә туры килә. Матди мөмкинлеккә килгәндә, ул хаҗның бәясен хәләл акчасы белән түләргә тиеш. Хаҗ юлламасын аңа балалары, туганнары бүләк итә ала.

:: Кредит алып, бурычка батып, хаҗга бару рөхсәт ителәме?

– Асылда, банктан акча алып, хаҗ кылу дөрес булмый. Кредитка алынган акчаны процентлар белән кайтарырга туры килә, димәк, бу акча хәрәм санала. Риба – ислам динендә зур гөнаһ. Әгәр дә хаҗга барырга теләге зур булып, күпмедер акчасы җитмәсә һәм аны кайткач түләргә мөмкинлеге булса, әҗәткә алырга була. Ул хаҗга киткәндә, минем белән берәр нәрсә була калса, машинамны яки башка милкемне сатып, бурычымны түләрсез, дип васыять әйтеп калдырырга бурычлы. Шул ук вакытта ул хаҗдан әйләнеп кайтканчы гаиләсе акчага тилмереп утырырга да тиеш түгел. Ә инде кешенең акчасы да, мөмкинлеге дә бар икән, ул хаҗ кылуны кичектермәсен иде. Киләсе елга аның белән нәрсә буласы билгесез бит. Хаҗ кылуны гел-гел кичектереп килеп, әлеге гыйбадәтне үтәүдән колак кагарга да мөмкин.

:: Кайберәүләр үзләре урынына кемнедер хаҗга җибәрә. Хәлле, бай кешеләр шулай эшли, гадәттә. Бу дөрес гамәлме?

– Хаҗ бары тик бер кеше өчен генә кылына. Әгәр үзең хаҗ кылган булсаң, башка кеше өчен хаҗны кылырга ярый. Шулай ук үлгән мөселман кешесе өчен хаҗны ниятләп кылырга мөмкин.

:: Олы һәм кече хаҗ бар. Алар аерыламы?

– Гомрә, ягъни кече хаҗда ихрам киясең, таваф, сәгый кыласың, чәч кырдырасың һәм ихрам халәтеннән чыгасың. Олы хаҗга Мина һәм Мөздәлифә үзәнлегендә төн куну, Гарәфәт үзәнлегендә тору, таш ату, корбан чалу да өстәлә. Олы хаҗ – фарыз, кече хаҗ сөннәт булып тора. Олы хаҗга барган кеше икесен дә кыла булып чыга. Олы хаҗны кылмаган кеше иң беренче чиратта олы хаҗга барырга ашыксын. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә, гомрә белән олы хаҗны аралаштырыгыз, диелә. Олы хаҗдан соң гомрә хаҗын күпме телисез, шулкадәр кылырга була. Кече хаҗны теләсә кайсы вакытта кылырга мөмкин, ләкин рамазан аенда кылу хәерлерәк, чөнки Мөхәммәд (с.г.в.), рамазан аенда гомрә кылу минем белән бергә хаҗ кылуга тиң, дигән.



islam.ru

:: Хаҗны еш кына кыямәтнең репетициясе дип тә атыйлар. Ни өчен шулай икән?

– Бер урында берьюлы төрле милләтләрдән әллә ничә миллион кеше җыела. Һәркем үзен мәхшәр мәйданында Аллаһы Тәгалә каршында басып торган кебек хис итәчәк, шуңа күрә шулай әйтелә дә.

:: Хаҗга ничә тапкыр барсаң да ярыймы?

– Пәйгамбәребездән (с.г.в.) аның бер сәхәбәсе: «Аллаһның Илчесе, хаҗ кылу ел саен үтәлергә тиешме, әллә гомергә бер тапкырмы?» – дип сораган һәм: «Бер тапкыр гына, тик кемнең мөмкинлеге бар, аңа күбрәк тә мөмкин», – дигән җавап алган.

:: Хаҗ сәфәрен бүләк итәргә ярыймы?

– Әлбәттә, динебез хаҗ юлламаларын бүләк итүне хуплый, чөнки бу кешеләргә хаҗ кылу мөмкинлеген тудыра. Кайберәүләр ел саен хаҗга бара бит. Андыйларга, бәлки, башка кешеләрне хаҗ белән сөендерү дә әҗер-саваплы булыр иде. Шуңа күрә бүләк ителгән хаҗ дөрес саналыр.

Белеп тор!

Җомга намазы әдәпләре

Илдар Мөхәммәтҗанов

- Намаз вакыты кергәнче, аңа әзерлек эшләрен тәмамларга.
- Вакыт керү белән үк, тәһарәтләнергә һәм иртәрәк мәчеткә китәргә.
- Госелләнергә.
- Чиста киемнәр кияргә.
- Тиешле күләмдә исле май кулланырга.
- Аз сөйләшергә.
- Һәрдаим Аллаһы Тәгаләне зекер итеп торырга.
- Имамга якынрак утырырга.
- Хөтбәне сөйләшмичә генә тыңларга.
- Намаз укыганнан соң гыйлем алырга юнәлергә.
- Йөргәндә салмак кына атларга.
- Адымнар зур булмасын.
- Башны бераз алга ияргә.
- Игелек эшләүчеләргә мактаулар әйтергә.
- Мәчеткә күркәм йөз белән керергә.
- Кешеләрнең сәламнәренә җавап бирергә.
- Хатыйп минбәргә менгәннән соң намаз укымаска.
- Хатыйп җәмәгатькә сәлам биргәндә, аның сәламенә җавап кайтарырга.
- Сөйләшмәскә.
- Хөтбәне бар күңелне биреп тыңларга һәм нәсыйхәтләрне кабул итәргә.
- Хатыйп җәмәгатькә борылып хөтбә сөйли башлаганнан соң, як-якка борылмаска. Хатыйп минбәрдән төшмичә һәм мөәзин камәтне төшереп бетермичә, намаз укырга тотынмаска.

(Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Газалиның «Әдәпләр» китабыннан алынды)

Гыйбрәт ал!

Чын дус кулыннан агу да – җимеш

Локман Хәкимнең бер дусты булган, ул аны шулкадәр хөрмәт иткән, ризыгын да иң элек аңа тәкъдим иткән. Бервакыт дустына кавын китергәннәр. Ул, кавынны кисеп, Локман Хәкимгә биргән, тегесе бик тәмләп ашый башлаган. Аңа кызыгып дусты да ашый башлаган икән, кавын авызга алгысыз әче булган. Гаҗәпләнеп: «Ни өчен әче дип зарланмадың?» – дигән. «Мин кавынга түгел, бирүче кулга игътибар иттем. Чын дус кулында әче әйбер дә татлы була, чын дус янында караңгылык та яктырып китә, авырлыклар да җиңеләя», – дигән Локман Хәким.

(«Локман Хәким нәсыйхәтләре» китабыннан)

pixabay.com

КӨРӘШЧЕ БУЛАТ МУСИН:
«УҢЫШ ТӘРТИПТӘН БАШЛАНА»

Соңгы арада Сабан туйлары турында бик күп язылды. Бәйрәм күрке – көрәш тә еш телгә алынды. Көрәшчеләр ни хәлдә соң? Көрәш буенча спорт остасы Булат МУСИН белән «урак өсте»нә берникадәр йомгак ясап, яңалыклары, откан тәкәләре, авыл Сабан туйлары турында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Хәлләр яхшы. Сабан туйлары гөрләгәндә, көрәшчеләрнең хәле начар була алмый инде ул (*көлә*). Бәйрәмнән бәйрәмгә йөреп торган чагыбыз әле.

:: Быелгы Сабантуйлы сезон нәтиҗәле булдымы? Имгәнү, җәрәхәтләрсез генә уздырып җибәрә алдыңмы?
– Андый куркыныч имгәнүләр булмады. Дөресен генә әйткәндә, Сабантуйларда көрәшү шактый куркыныч ул. Профессиональ көрәшчеләргә бигрәк тә. Җылынырга, ягъни разминка ясарга мөмкинлек юк диярлек. Гел урамда, кояш астында торасың. Шуңа күрә артык мавыкмыйча, сакланып кына көрәшергә тырышабыз.

Нәтиҗәләргә килгәндә, быел Казан Сабан туенда абсолют батыр исемен алдым. Күптәнге хыялым, максатым иде бу җиңү. Федераль Сабан туе, Бөтенроссия авыл Сабан туе, шахтерлар Сабан туенда да үз авырлыгымда җиңдем. Ләкин андый бәйрәмнәрдә бил алышуны Россия күләмендәге турнир дип атыйлар. Шуңа да Сабан туенда көрәшү түгел, ярышка барган кебек кабул ителә алар.

:: Ә авыл Сабан туйларында көрәштеңме быел?
– Авылда быел бер генә тапкыр көрәшергә насыйп булды. Анысы да Казан тирәсендәге бер авыл иде. Үзебезнең якларга – Яңа Чишмәдәге бәйрәмгә кайта алмадым.

:: Авылда көрәшү барыбер башкачарактыр инде?
– Авыл халкы бәйрәмгә чын-чынлап, рәхәтләнеп ял итәргә чыга. Көрәшне дә бирелеп, чын күңелдән җан атып күзәтәләр анда. Әйе, шәһәр белән авыл мәйданы арасындагы аерма сизелә шул.

:: Саладагы бәйрәмнәргә профессиональ көрәшчеләрне кертмәскә кирәк, диләр...
– Шактый бәхәсле мәсьәлә инде бу. Үз авылында мәйданга чыгып, бил алышучы егетләр бик күп түгел бит хәзер. Алар да көрәшмәсә, безне дә кертмәсәләр, авыл Сабан туйларында көрәш бетә дигән сүз бит инде ул.

:: Көрәшеп җиңгән бүләкләрең хәйран җыелгандыр инде. Аларга урынны каян табып бетерәсез?
– Укытучы бит ул һәрвакыт дәүләттән игътибар артыр, яхшы хезмәт хакы булыр, бюрократик киртәләр җимерелер дип хыяллана. Аның өчен иң беренче чиратта укучыларның тәрбиясе мөһим. Бала күпме генә белемле булса да, тәрбиядән башка ерак китеп булмый. Соңгы утыз елда мәгарифнең фәлсәфәсе үзгәрде. Әлеге өлкә хезмәт күрсәтүгә әйләнеп калды. Гаепләп тә булмый: тормыш та, кыйммәтләр дә башкача хәзер, цифрлы дөнья барлыкка килде. Тик күпмилләтле традицион белем бирү системасын яшьләргә тапшыру чылбырын берничек тә өзәргә ярамый. Бу яктан проблемаларны хәл итәсе бар әле. Укытучылар менә шул байлыкны яшь буынга бирүче төп звено булыр һәм шул ук вакытта замана белән бергә атлар дип өметләнәм. Мөгаллимнәр алдында тәрбия һәм укытуның эчтәлеген яңарту бурычлары тора. Югары технологияләр үскән тармаклар, бигрәк тә сәнәгать өчен дә булдыклы, сәләтле яшьләр килүен көтә. Бу – замана таләбе. Моны бары укытучылар гына әзерли ала. Мәктәптә дә, педагогик вузларда да базар икътисадын күздә тотып, укыту программалары үзгәрер. Без үзебез дә шуңа күчәргә әзер. КФУны Россиядә генә түгел, дөнья күләмендә дә таныйлар. Укытучылар әзерләү буенча «Иң яхшы 100 вуз» исемлегенә кердек.
Укытучының дәрәҗәсен арттыру социаль ярдәмнән башка да булмый. Педагоглар лаеклы хезмәт хакы алырга тиеш. Укытучы үзенең кирәклеген тойсын, дәүләт тарафыннан якланган булсын иде. Мәктәпләрдә укытучылар җитми. Яшь укытучыларны мәктәпләргә беркетү мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Без яшьләрдән: «Ник китәсез?» – дип сораганда, әти-әниләр белән уртак тел табу җиңел түгел, тәмам туйдырдылар инде, дип әйтүчеләр дә аз түгел. Берәү дә бит табибны дөрес итеп операция ясарга, пешекчене аш пешерергә, чәчтарашны чәч кисәргә килеп өйрәтеп йөрми. Нигә әле укытучы белеме булмаган әти-әниләр мәктәп эшенә кысылырга тиеш? Хезмәт хаклары да кызыктырырлык түгел. Шуңа күрә алар репетиторлык белән шөгыльләнергә мәҗбүр. «Безнең яшь укытучы» гранты бетерелде, кире кайтарсыннар иде.

Белешмә

Татарстанның белем бирү оешмаларында барлыгы 64 мең педагогик хезмәткәр эшли. Шуның 32 меңгә якыны – укытучы, 16 меңнән артыгагы – тәрбияче. Укытучының уртача яше 48не тәшкил итә. Пенсия яшендәге укытучылар – 20 процент чамасы.

ТЕРЕЛЕП КЕНӘ ЭШ БЕТМИ

Чирдән бигрәк, ул калдырган эз куркынычрак. Коронавирус турында сөйләгәндә, бу фикерне еш ишетергә туры килә. Соңгы арада бигрәк тә. Моннан ике ел элек ковид дигән зәхмәтнең нинди билгеләр белән узуын аңларга тырышсак, бүген аның нәтиҗәләрен барлыйбыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Коронавирус белән авырып терелдем дип тынычланган кешеләрнең күбесе бүген кан басымы үйнау, чәч коелу, күңел төшенкелеге кебек моңарчы күренмәгән хәлләрдән зарлана. Табиблар исә чирдән соң андый өзлегүләрне кисәтү өчен җентекле диспансеризация узарга киңәш итә.

Яшерен-батырын түгел, килеп туган вазгыять аркасында, соңгы ике елда телдән төшмәгән коронавирус та онытылды кебек. Рәсми саннарга күз салсаң да, чир чигенә барган сыман. Әйтик, бу юлларны язганда бер тәүлек эчендә Татарстанда 43 кешенең коронавирус йоктырганы билгеле иде. Язын Татарстанда барлык ковид госпитальләре ябылды. Казанда «кызыл зона» 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсендә генә эшләп килә. Анда да ятак урыннар саны 100дән артмый. Чагыштыру өчен: ковид котырган иң хәтәр чорда аларның саны 650гә җиткән иде.

Әмма белгечләр тынычланырга иртәрәк дип саный. Татарстанның баш терапевты Диана Габделганиева сүзләре белән әйтсәк, коронавирус фаразлауга бирешә торган чир түгел. «Без көтү һәм ревакцинация режимында яшибез. Хәзер төп игътибар җентекле диспансеризациягә бирелә», – ди белгеч.

Билгеле булганча, узган елның 1 июленнән Россиядә җентекле диспансеризация дигән төшенчә гамәлгә керде. Ул коронавирус белән авырып терелгән кешенең сәламәтлеген тулысынча тикшерү, мәкерле чир аркасында өзлегүләрне кисәтү өчен уздырыла. Аны гадәти диспансеризация белән бутарга ярамый. Яше тулган кеше бу тикшеренүне әле дә элеккеге тәртиптә уза ала. Җентеклесе исә аның бер төре генә булып тора.

Быел Татарстанда 245 меңнән артык кеше коронавирустан соң җентекле диспансеризация узачак. Татарстан буенча мәҗбүри медицина иминияте фонды җитәкчесе урынбасары Гүзәлия Зәкәриева сүзләренә караганда, хәзерге вакытта 46 меңнән артык кеше бу төр тикшерелүне үткән инде.

Үзе файдалы, үзе бушка

Әлмәттә яшәүче Гөлназ Нәгыймова күптән түгел генә җентекле диспансеризация узган. Коронавирусны җиңелчә формада уздырган ул. Хастаханәгә дә мөрәҗәгать итмәгән. Даруханәдән алган экспресс-тест нәтиҗәләре уңай нәтиҗә күрсәткәч, коронавирус белән авыручылар өчен каралган стандарт даруларны эчеп дәваланган. «Чир котырган чакта хастаханә юлын таптыйсы килмәде. Өстәвенә температурам да бер көн генә югары торды. Икенче көнгә ис, тәм тоймый башладым. Башка бернинди билгеләр дә күзәтелмәде. Экспресс-тест нәтиҗәләре уңай нәтиҗә күрсәткәч, ковид вакытында тиешле даруларны эчтем дә шуның белән шул. Өйдә торып эшләгәч, кеше янына да чыгып йөрмәдем. Әмма соңгы арада кан басымым үйный башлады», – ди ул.

Авырганда үзе теркәлгән адрес буенча табибка мөрәҗәгать итмәгәч, ул коронавирус белән авыручылар исемлегендә юк. Шуңа күрә участок терапевтына барган Гөлназ. Шикләре дөрес булып чыккан аның. Кан басымы үйнау, коронавирус нәтиҗәсе икән. «Хәзер табиб язып биргән даруларны эчәм. Ике атнадан тагын килергә кушты», – ди ул. Гөлназ диспансеризацияне матди яктан да отышлы дип таба. «Бу тикшеренүләрнең барысын да түләүле клиникада узсам, анализларга гына да ким дигәндә ике мең сум киткән булыр иде. Табибка күренүләр белән бергә ун мең сумга басар иде», – ди Гөлназ.

Баулы районы Мортаза фельдшер-акушерлык пунктын җитәкләүче Рәзинә Мөгыйнова да шул фикердә. «Ковид белән авырып терелгән кеше нинди сират күпере кичте бит, күбесе үлемнән калды. Андыйларга сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Безнең авыл юл чатында гына тора, кайтып-китеп йөрүчеләр күп. Шуңа күрә авылда ковидтан үлем-китем очраклары күп булыр дип куркыккан идем. Куркуларым юкка булып чыкты», – дип сөенә ул.

Рәзинә Мөгыйнова бүген 262 кеше яшәгән Мортаза авылы халкына хезмәт күрсәтә. Җәйгә кунакка кайтучылар белән бергә аларның саны 500гә җитә икән. Рәзинә ханым хезмәт күрсәткән җирлектә нибары ике кеше генә коронавирус белән авырган. Калганнарына пневмония диагнозы куелган. «Коронавирус белән авырган шушы ике кеше җентекле диспансеризацияне күптәннән үтеп куйды. Үзебез чакырып алдык. Алар өчен хәзер җаным тыныч», – ди белгеч.

Яшерен куркыныч

7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе баш табибы Ольга Богданова әйтүенчә, коронавирус белән авырган кешегә сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Чир үтте, терелдем, дип тынычланырга ярамый. «Ковид белән авырып терелгән кеше еш кына организмында күзгә ташланып торган үзгәрешләр булганда гына табибка мөрәҗәгать итә. Алар, гадәттә, чәч коелу, йокысызлык, күңел төшенкелегеннән зарлана. Әмма мондый өзлегүләрдән кеше үлми. Коронавирусның кеше гомеренә куркыныч тудырган, инвалидлыкка китерә алган нәтиҗәләре, гадәттә, үзен алай ачыктан-ачык сиздерми, организмда яшеренгән була. Алар билгеле бер вакыт үткәннән соң гына күренә. Җентекле диспансеризация ковидтан соңгы әнә шундый куркыныч өзлегүләрне кисәтеп, вакытында ачыкларга ярдәм итә дә инде», – ди белгеч. Соңгы арада коронавирус белән авырып терелүчеләр арасында кан басымы үйнаудан, аппетит булмаудан зарланучылар да очрый башлаган.

Ольга Богданова сүзләренә караганда, ковидтан соң өзлегүләр авырып терелгәннән соң ике ай, хәтта ярты ел үткәч кенә дә күзәтелергә мөмкин. Ул чирне авыр формада гына түгел, хәтта авырганын үзе дә белмичә аягөсте генә үткәргән кешеләрне дә аяктан егарга мөмкин. «Яман шеш, шикәр чире диагнозы куелган, йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интеккән кешеләр коронавирус белән дә авырган очракта, иң беренче чиратта, җентекле диспансеризация узарга тиеш», – ди баш табиб.

Ике баскыч узасы

Җентекле диспансеризацияне узу өчен, коронавирус белән авырганнан соң ким дигәндә ике ай узгач, яшәү урыны буенча теркәлгән хастаханәгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аны коронавирус диагнозы рәсми рәвештә расланган кешеләр һәм ПЦР-тесты уңай нәтиҗә бирмәсә дә, ковид белән авырган кешеләр уза ала.

«Бу төр диспансеризация ике этаптан тора. Беренче этапны һәркем үтәргә тиеш. Монда иң элек анкета тутырыла. Анда язылганнарга нигезләнеп, табиб кешенең ковидны ни рәвешле, нинди билгеләр белән уздыруын күзаллый ала», – ди Ольга Богданова. Алга таба сатурация күрсәткече, ягъни кандагы кислород дәрәҗәсе тикшерелә. Ул 94 проценттан да түбәнрәк булса, кешене компьютер томографиясенә озаталар.

Аннары кеше алты минут буе атлап йөрергә тиеш. Сау-сәламәт кеше шушы вакыт эчендә 550 метр араны бернинди тын кысылу, йөрәк кагуларсыз уза. «Бу тестны уза алмаган кешегә эхокардиография (ЭХО) ясала», – ди табиб.

Җентекле диспансеризациянең беренче этабында гомуми кан анализы да тапшырырга кирәк. Ел дәвамында рентген узмаган кешегә бу тикшеренүне дә үтәргә туры киләчәк. Әгәр коронавирус белән авырган кешенең билгеле бер зарлары булса, әйтик, ул шул ук чәч коелудан интексә, ул чәч табибы – трихологка да күренергә тиеш булачак. Алда телгә алынган барлык анализ, тикшеренүләр нәтиҗәсенә таянып, терапевт өстәмә тикшеренү узарга кирәкмәюкмы икәнлеген ачыклаячак.

«Коронавирусны авыр һәм уртача авырлыкта уздырган кешеләрнең канындагы D-димер күрсәткече тикшерелә. Ул нормадан 1,5–2 тапкыр югарырак булган очракта, кеше җентекле диспансеризациянең икенче этабын узарга тиеш. Бу очракта аяктагы кан тамырлары тикшереләчәк. Ул тромб килеп чыгуны кисәтү өчен эшләнә. Сатурация дәрәҗәсе 94 проценттан түбәнрәк булганда компьютер томографиясе белән йөрәккә УЗИ ясала», – ди Ольга Богданова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Җентекле диспансеризация турында

● **Кемнәр уза ала?**
– коронавирус диагнозы расланган, авырып терелгәннән соң ким дигәндә 60 көн вакыт үткән, 18 яшьтән өлкәнрәк кешеләр;
– ПЦР-тесты уңай нәтиҗә бирмәсә дә, ковид белән авырган кешеләр.

● **Нидән гыйбарәт?**
I этап:
– гомуми һәм биохимик кан анализы;
– канның кислород белән ни дәрәҗәдә туенганлыгын ачыклау;
– алты минутлык йөрешне тикшерүче тест (кешенең физик авырлыкны ничек күтәрүен ачыкларга ярдәм итә);
– спирометрия (сулаган һәм чыгарган һава күләмен, аның тын юллары буйлап нинди тизлектә узуын ачыклый);
– күкрәк читлегенә рентген ясала;
– кандагы D-димер күрсәткече тикшерелә (тромбны кисәтү өчен)
– анализ, тикшеренү нәтиҗәләре белән терапевтка күренү.
II этап:
– эхокардиография (ЭХОКГ) уздырыла;
– үпкәләргә компьютер томографиясе ясала;
– аяктагы кан тамырлары тикшерелә;
– тикшерү барышында кешедә хроник авырулар барлыгы яки аларның килеп чыгу ихтималы зур булган очракта дәвалау курсы билгеләнәчәк.

● **Кая мөрәҗәгать итәргә?**
– җентекле диспансеризациягә үзегез беркетелгән хастаханәгә барып яки Дәүләт хезмәтләре порталы (gosuslugi.ru) аша язылырга мөмкин. Портал аша эш иткәндә, диспансеризацияне кайсы адрес буенча урнашкан хастаханәдә узуыгызны, үзегез турында шәхси мәгълүматны күрсәтеп, сәламәтлек турындагы махсус анкетаны тутырырга, тикшерелү узачак көнне сайлап язылырга кирәк.

Сүз уңаеннан

Россия Хезмәт кодексының 185.1 маддәсе нигезендә, эш бирүче диспансеризация узган өчен түләнә торган ял көне бирергә тиеш. 40 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләргә ул елга бер тапкыр, пенсия һәм пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә елга ике көн, калган хезмәткәрләргә өч елга бер тапкыр бирелергә тиеш. Бу ял көнен алу өчен, эш бирүче белән диспансеризация узачак көнне килештереп, гариза язарга кирәк. Бу көнне дөрестән дә табиб юлын таптавыгызны исә хастаханәдән алынган белешмә ярдәмендә расларга туры киләчәк.

ДАНИИЛНЫ ӨМЕТ ЯШӘТӘ

Казанда яшәүче 19 яшьлек Даниил Вахитов моннан ике ел элек урын өстенә кала. Яңа гына 11 нче сыйныфны тәмамлаган егет күңелсез хәлгә тарый. 2020 елның 15 июне аның язмышын үзгәртә дә куя.

Егет чыгарылыш кичәсендә сыйныфташлары белән су коенырга бара. Кечкенәдән бассейнда йөзгән егетне бәла нәкъ шунда көтеп тора. Суга чумганда муенын сындыра ул. Редакциягә Даниилның әнисе Мария ханым мөрәҗәгать итте. «Улымны бик яшәтәсем, аягына бастырасым килә», – диде ул. Ә бит моннан ике ел элек табиблар, улыгыз яшәмәячәк, дип, ананың өметен өзгән була.

– Аллага шөкер, минем догаларым кабул булды. Ходайдан балама гомер сорадым. Ул исән, инвалид арбасында утырса да, янымда, – ди әнисе. – Даниил ике катлаулы операция кичерде. Алардан соң хәрәкәтләнү бөтенләй бетте. Табиблар берни вәгъдә итә алмады. Муеныннан кала, башка бер әгъзасы да хәрәкәтләнмәячәк, дигәннәр иде. Әммә без күңелне төшермәдек. Ана күңелен берни алдый алмый. Мин сиздем һәм ышандым. Улымның йөреп китәсен дә көтәм әле.

Мария ханым улын тернәкләндерү өчен бар көчен куя. Елап, өметсезлеккә бирелеп утырмый ул. Тизрәк таныш-белешләреннән улы кебек җәрәхәт алган кешеләрнең кайда дәвалануын сораша да Даниилны йөртә башлый. Шөкер, яшь организм үзенекен итә. Әкренләп улының аяклары тоя, куллары селкенә башлый. Яңадан сөйләшергә өйрәнә. Инде хәзер табиблар да, даими тернәкләнү үтсә, егет алга таба аякка басарга мөмкин, диләр. Ә Мариягә шул гына кирәк тә! Ул баласының ничек тә үз-үзен йөртерлек булуын тели. Ике ел буе күзенә карап ярдәм көткән улының ниләр кичергәнен дә яхшы аңлый ул. Ә бит теге вакыттагы чыгарылыш кичәсендә Даниил бик зур хыяллар белән яна. Кулына аттестат алып, аның да, башкалар кебек, югары уку йортына керәсе, белем аласы килә. Тик бар да хыялда гына кала. Әти-әнисенең ныклы терәге Даниилга яшәр көч бирә. Егет гаиләсенә, якыннарына, дусларына рәхмәтле икәнен яшерми. Әнисе дә ике ел дәвамында матди ярдәм күрсәткән һәркемгә саулык тели.

– Сәламәтлек өчен күпме акча кирәк?! – ди ул. – Үз башыңа төшмәгәндә, кеше кайгысын читләтеп узасың икән. Гаиләбезгә хәсрәт килгәч, без бөтенләй үзгәрдек. Бер уйламаган җирдән ярдәм килеп куя. Әммә ул акча озакка җитми. Улыбызга һәрдаим дәвалану кирәк. Әгәр берәр тапкыр тернәкләндерү курсын калдырабыз икән, куллар-аяклар киреләнә башлый. Аларны тыңлатыр өчен яңадан вакыт кирәк. Кешедән килгәнне генә көтеп утырмыйбыз, үзебез дә тырышабыз. Әммә ярдәмнән башка ерак китеп булмый шул. Әле бит безнең 11 яшьлек кызыбыз да бар. Улыма гел ярдәм кирәк булгач, эштән дә китәргә туры килде. Тормышны алып бару ирем Раил өстендә.

Даниилга туры килә торган үзәк Мәскәүдә урнашкан. Тик анда дәвалану бик кыйммәт. Бер ай тернәкләндерү узган өчен 1,5 миллион сум акча түлисе. Акча булмагач, Даниилның мотоциклын сатмакчы булганнар. Әммә ул каршы килгән. Аякка баскач, мин анда йөреячәкмен, ди икән. Ә кем белә? Бергәләп тотынсак, без бу хыялны чынга ашырачакбыз бит! Әнә шуңа да Мария газета укучылардан ярдәм сорый.

ДАНИИЛГА БУЛЫШЫРГА ТЕЛӘГӘН КЕШЕЛӘР ӨЧЕН ИСӘП-ХИСАП РЕКВИЗИТЛАРЫ:
Вахитов Даниил Раил улы исемендәге **4276 6200 3883 4986**
Саклык банкы картасы **8-960-060-24-27** телефон номерына бәйләнгән.

ЯЗМЫШЫМА КӨН ДӘ РӘХМӘТ УКЫЙМ

Кукмара районының Вахит авылында туып-үскән Нияз Кәримуллин әнә шулай ди. Кайчандыр тернәкләндерү үзәгенә йөргәндә, ул тормышта үз юлын табу, биек үрләр яулау хакында уйлап та карамый. Бирегә ул сәламәтлеген ныгытырга килә. Әммә савыгып кына калмый, тормыш авырлыкларын җиңәргә дә өйрәнә.

– Кечкенәдән тотлыгам мин. Яз көне өебезгә су кергән була. Әти-әнием шуны суыртканда, мин базга егылып төшкәнмен. Менә шуннан бирле тотлыгам инде, – ди ул. – Кечкенәдән мине табибларга йөрттеләр. Янәсе, кимчелегемне бетереп булмасмы? Дәваланган чакта сөйләшү үзгәрә, тотлыгу кимеп тора. Аннары ике ай узуга, кире үз хәлемә кайта идем. Мин бу халәтемә ияләндем инде. Шөкер, юлымда яхшы кешеләр очрап, авырлыкларны җиңәргә, үземне ничек бар, шулай яратырга, кабул итәргә өйрәндем. Тормышта туры юл күрсәтүче кешеләрем күп булды. Мин әле дә аларга рәхмәт укыйм.

Нияз кечкенәдән җырга-моңга гашыйк була. Әммә сәхнәгә чыгып җырлау хакында хыялланмый да. Ә тормыш башка яктан ишекләрне ача. Районның социаль яклау бүлеге җитәкчесе Светлана Җамалиева Ниязның җырлавын ишетеп, аны сәхнәгә алып чыга.

– Бу минем өчен зур җиңү булды. Кечкенәдән иҗатка гашыйк кешемен. Җырларга, биергә, күңел кичерешләремне кәгазь битләренә төшерергә яратам. Вахит авылы балалар бакчасына йөргәндә үк музыка җитәкчесе Сәкинә апа Ибраһимова сәләтләребезне ачарга ярдәм иткән иде безгә. Аннары мин «Шәфкать» тернәкләндерү үзәгенә килеп эләктем. Әле дә бу үзәккә рәхәтләнеп йөрер идем. Тик яшем туры килми, – ди ул.

Матур җырлаганын күреп, тернәкләндерү үзәгенең ул чактагы музыка җитәкчесе Илмира Ханнанова сәнгать мәктәбенә керергә киңәш итә. Аннары ул үз авылларында

эшләп килүче «Җәүһәр» җыр һәм бию фольклор ансамбленә йөри башлый.

Ниязның мәктәптә укыганда ирешкән уңышлары да күп. Казан дәүләт мәдәният институтына укырга кереп, аны да тәмамлый. Тик торганы юк аның.

– Хәзер өч эштә эшлим. Татарстан Мәдәният министрлыгының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәгендә режиссер, Кукмара балалар музыка мәктәбендә укытучы, «Сандугач» вокаль ансамбле җитәкчесе, Вахит авылы мәдәният йортында оештыручы, «Тургай» бию төркеме җитәкчесе булып торам. Әлеге оешмаларның җитәкчеләре, коллегаларым белән бер-беребезне аңлап, матур итеп, алардан үрнәк алып, киңәшләр сорап эшлим, – ди ул. – Һәр эштә тырышлык кирәк. Үзеңне күрсәтмәсәң, синдә ышаныч булмаячак. Мин исә, теләгән юнәлешемдә булгач, рәхәтләнеп иҗатка чумам. Аннары тагын шунысы бар: җырлаганда тотлыкмыйм. Җыр сузылгач, сулыш яхшыра. Кешеләр белән аралашканда сузып сөйләшергә тырышам. Шулай итсәң, тотлыгу бетә. Шөкер, якыннарым да, башкалар да кимчелегемә игътибар итмиләр, сөйләгәнемне тыңлыйлар.

Ниязның гаилә корганына да 2 ел инде. Хатыны Айгөл белән Назгөл исемле кыз сөяләр. Әммә күңел ярасы да бар аның. Узган ел коронавирус авыруы әтисен якты дөньядан алып китте.

– Әтиебез бик тә кешелекле, ярдәмчел иде. Әле дә аның юклыгына ышанып бетеп булмый. 54 яшендә генә иде әле. Матур итеп юбилеен үткәрергә җыенган идек. Гомер бәйрәмен түгел, ашларын уздырырга туры килде, – дип сөйли Нияз. – Тормышта минем уңышларга ирешәсемә ышанучы, канатландырып, үсендереп торучы кешеләр – әти белән әни. Әти һәрчак: «Гаиләбезнең, нәселебезнең дәрәҗәсен төшермә, югарыга атла», – дип әйтә килде, әле хәзер дә аның киңәшләрен тоеп яшим, тырышып хезмәт куям.

Нияз әнисенә дә рәхмәтле. Алар сеңлесе Гөлшат белән әниләренә терәк булырга тырышалар. Бар эштә бергә алар. Ришат абый күкләрдән карап сөенәдер. Сөенмәслек тә түгел! Ә бит берәү дә Ниязның сәхнәгә чыгып җырлавына, югары белем алып, инде хәзер аспирантурада укуына ышанмаган була. Үзе әйтмешли, үҗәтлек һәм тырышлык үз эшен эшли.

– Син ничә эштә эшлисең, армыйсыңмы, ничек җитешәсең, диләр. Тормышта барысына да өлгерергә кирәк. Күктән төшкәнне көтеп утырып булмый. Матур яшисең килсә, җаен табасың инде. Синең өчен берәү дә эшләмәячәк. Тормыш – үз кулыңда, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЭЛЬМИР НИЗАМОВ:
«МИН ҺАМАН МУЗЫКАЛЬ ТЕАТР ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАМ»

Ринат Җиганшин

Иҗатта чикләр булырга тиешме? Татарча музыка ул – нинди музыка? Югалып барган мирасны ничек саклап калырга? Ни өчен без аерылып торган кешеләрне яратмыйбыз? Болар һәм башка мәсьәләләр хакында композитор Эльмир НИЗАМОВ белән сөйләштек.

:: Театр, кино, эстрадага музыка язу, шул ук вакытта күләмле әсәрләр иҗат итү – боларның барысын да ничек колачлап була? Табигый хәл түгел бит инде, килешәсеңдер?

– Бу күренешне табигый дип әйтә алмыйм, чөнки күп композиторлар чынлап та бер юнәлештә иҗат итүне сайлый. Гадәттә шулай инде. Әмма бу заманда үзеңә ниндидер чик-кысалар кую бик үк дөрес тә түгелдер. Миңа үземне төрле юнәлешләрдә сынап карау, төрле яктан ачу кызыклы. Театр өлкәсен генә алсак та, аның эчендә генә дә күпме юнәлеш бит. Һәр спектакль – тәҗрибә. Бер спектакль, әйтик, опера стилендә иҗат ителсә, икенчесендә – заманча рэп, өченчесендә – фольклор, дүртенчесендә – Шекспир дөньясы… Аларның һәрберсе – кечкенә генә ачыш. Бәлки шуңа күрәдер, театр дөньясы миңа якын. Ул да мине үз итә дип сизәм.

Төрле юнәлешләрдә эшләүче композиторлар бар, ләкин күп түгел. Күпчелеге, «мин симфонияләр язам, җыр дәрәҗәсенә төшмим» яки «мин җырлар язам, башкасына тыгылып тормыйм» дигән фикер белән эш итә. Ә мин аларны аермыйм. Хәзер шундый заман: элитар сәнгать белән массачыл сәнгать арасындагы чик юылды, дисәк тә була. Мисалга «Кара пулат» операсын алыйк. Ул – бөтен яклап элитар сәнгать әсәре. Шул ук вакытта аны гади халык та кабул итте. Үзем дә иҗатымда шушы чикне юкка чыгарырга омтылам.

:: Музыкасы татарча түгел, дип әйткәннәре дә бар, татарча музыка, синеңчә, нинди була?

– Һәр милләтнең фольклор хәзинәсе һәм әлеге бай мирасның үз традицияләре бар. Композитор исә фольклорга нигезләнсә дә, барыбер үз музыка дөньясын төзи. Ул халык музыкасын язмый, ул үз музыкасын иҗат итә. Әлбәттә, иҗат кешесенә төрле факторлар тәэсир итә. Бу татар музыкасы да, чит ил музыкасы да булырга мөмкин. Аларның микъдарын һәр кеше үзе билгели. Музыкасы татарча түгел, дип әйткәндә, мине кем белән чагыштыралар икән соң? Сәйдәшев белән чагыштыралар икән, мин бит Сәйдәшев булырга тиеш түгел. Хәер, аңа да заманында тәнкыйть эләкми калмагандыр. Әйтик, татарларга вальс нәрсәгә кирәк булган, дип әйтергә була. Вальс бит ул – чеп-чи Европа жанры. Ә Сәйдәшев шундый итеп иҗат иткән, еллар үткәч, без Сәйдәшев вальсларын чын татар музыка үрнәге дип кабул итәбез. Марш белән дә шул ук хәл.

:: Татар музыка сәнгате бүген ни хәлдә?

– Музыкаль процессның эчендә кайнаганлыктан, миңа объектив бәя бирү читенрәк. Эчтән караганда, музыка хәлен начар дип әйтә алмыйм, чөнки безнең республикада Дәүләт симфоник оркестры , «La Primavera» Казан камера оркестры, «Новая музыка» кебек бик көчле коллективларыбыз бар. Музыка сәнгате үсештә. Карагыз, кыска гына вакыт эчендә Камал һәм Тинчурин театрларында нинди көчле оркестр тупланды. Бу да бит – бик зур дәлил. Үз йөзе, үз юлы булган композиторларыбыз да бар. Әлбәттә, без күп түгел. Ә бит уйлап карасаң, авторларның кайчан күп булганы бар? Исемнәре тарихта калган, бүген дә музыкасы яңгыраган шәхесләрне барлыйк әле. Нәҗип Җиһановтан башласак, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин һәм башкалар – аларны барларга ике кул бармаклары җитә. Әлбәттә, музыка сәнгатенең проблемалары да җитәрлек. Мәсәлән, мин һаман да музыкаль театр турында хыялланам.

:: Хыялланып арымадыгызмы соң әле? Күпме сөйләнсә дә, эшнең кузгалганы юк бит?

– Минемчә, иртәме-соңмы, ул барыбер булачак. Тамчы тама-тама ташны тишә бит, безнең дә бу проблеманы гел күтәреп торуыбыз бушка булмас.

:: Зәвыклы музыканы киң катлау тыңлыймы?

– Музыканың өч башлангычы бар: беренчесе – автор, икенчесе – башкаручы, өченчесе – аны тыңлаучы. Әнә шул өченчесе булмаса, калган икесенең хезмәтендә мәгънә юк. Тыңлаучы нинди – музыка да шундый. Әйтик, менә зал буш, тамашачы килмәгән, ди. Анда яңгыраган музыка да үсә алмый дигән сүз бит инде. Шуңа күрә безгә бер генә юл кала: үз тамашачыбызны тәрбияләргә, аны үстерергә. Моны төрле фестивальләр, концертлар һәм радио-телевидение аша эшләргә мөмкин. Тик безнең радио-телевидение күбрәк коммерция юнәлешендә эшли. Анда финанс мөмкинлекләре булганнар гына эләгә ала. Еш кына зәвыклы җырчыларның иҗатларын күрсәтергә акчасы булмый. Шуңа күрә безгә әле бу юнәлештә эшләргә дә эшләргә.

:: Хәзерге шартларда үз әсәреңне халыкка җиткерә белергә дә кирәк бит әле. Элек ул пропаганда дип атала иде, хәзер башкача. Реклама белән үзең шөгыльләнәсеңме?

– Совет заманында бу эш белән дәүләт шөгыльләнгән, бүген дәүләттән андый ярдәм көтеп булмый. Хәер, хәзерге чорда һәркем үзенә генә таянырга кирәклеген аңлый. Чыннан да үзеңнән дә күп нәрсә тора бит. Шуңа күрә мин интернетта актив, чөнки миңа тыңлаучы белән минем арада элемтә булдыру бик мөһим. Музыкамны беркем дә ишетми икән, мин тынычлана алмыйм. Интернет бу яктан бик күп мөмкинлекләр ача. Тик кемдер аны булдыра алмый. Элеккеге заман моделе белән яшәүчеләр, мин бу эш белән шөгыльләнергә тиеш түгел, дип тә санарга мөмкин. Аларга, минем фәлән көнне концертым була, килегез, дип игълан элү тыйнаксызлык кебек тоела. Әгәр инде син шул юлны сайлыйсың икән, концертыңа йөрмәүләренә, музыкаңны белмәүләренә гаҗәпләнергә кирәкми.

> Музыка ул – иҗади яктан да, физик яктан да ныклык таләп итә торган өлкә. Мәсәлән, син көне-төне язасың, ә ул әсәр беркайда да яңгырамый. Күңел төшенкелегенә биреләсең. Менә шул вакытта бу сазлыктан арына белергә дә кирәк. Дөрес, мине яшьтән күреп алдылар. Ләкин холык буенча максималист булганга, үземнән гел канәгать булмадым.

:: Шунысы да бар: күләмле әсәрләрең сәхнәдә берничә тапкыр гына куела. Миңа калса, «Алтын Казан»ны да, яңадан сәхнәгә менгән «Кара пулат»ны да әллә ни күп тамашачы карый алмады. Проблема нәрсәдә?

– Моның сәбәпләре берничә. Беренчедән, әлеге дә баягы музыкаль театр булмау. Икенчедән… «Кара пулат» мисалын алсак, анда актерларның 90 проценты чакырулы. Аларга 5 спектакль өчен гонорар түләнгән, ә калганы билгесез. Бу спектакль беркемнең дә балансында түгел, ул һавада эленеп калган. Әгәр бу команда берәр театрда хезмәт хакы алып эшләсә, ул әсәр кабат-кабат куелыр иде.

:: Мәдәният министры Ирада Әюповадан: «Ни өчен опера театрында татар әсәрләре 11 тапкыр гына куелган?» – дип сорадылар. Син бу сорауга ничек җавап бирер идең?

– Опера театрының репертуар сәясәтен белмим, мин болай фаразлыйм: әгәр татар музыкаль әсәрләре шыгрым тулы заллар җыйса, алар күбрәк күрсәтелер иде. Әйтик, менә Камал театры премьераларына бөтен татар интеллигенциясе агыла, баскычларга утырып карыйлар. Шулкадәр кызыксыну анда! Ә музыкаль спектакльләрдә шул ук йөзләр күренми бит. Опера сәнгате безнең халыкка барыбер ераграк.

:: Күп кенә талантлар аз гына таныла башлагач, Мәскәүгә яки чит илгә күченә.   Ә нишләп син әле дә Казанда?

– Бер яктан, Казан белән генә чикләнәсе дә килми. Россия күләмендә дә, чит илдә дә эшлисе килә. Шулай эшләп караганым да бар инде. Әмма мин Казанга кирәклегемне сизәм. Республика ярдәм итә, иҗатташ дусларым бар, биредә иҗади мохит тә тотрыклы. Мин бит – татар, кая гына барсам да, күңел Казанга ашкына. Минем аны иҗатым белән баетасым килә.

Шунысы да бар: Казан – бик консерватив шәһәр. Биредә үз кеше булу өчен бик күп тырышырга кирәк. Бер ун еллап яшәгәч кенә мин үземә игътибар сизә башладым. Татарлар аерылып торган кешеләрне дә бик яратмыйлар. Без үз шәхесләребезне бәяләмибез. Концертларда әсәрнең авторлары, хәтта чыгыш ясаучының исемен дә әйтеп тормыйлар. Юкса танытырга кирәк. Талантлар аша милләтең дә үсә. Халык милләт булып җитешсен өчен аның бөек язучылары, композиторлары, шәхесләре булырга тиеш. Без шуларның иҗаты аша милләт турында күзаллыйбыз лабаса. Рус мәдәнияте дигәч, Пушкин, Достоевский күз алдына килә бит. Димәк, милләткә геройлар кирәк. Ә без үз геройларыбызны үстермибез.

:: Холкың буенча син нинди кеше?

– Ялгызым калганда, миңа бик рәхәт. Зур компанияләр яратмыйм. Дөрес, аралашырга яратам, үземне ачык кеше дип саныйм. Тагын мин үзсүзле. Бөтен кеше дә, дөрес эшләмисең, дип әйтеп торса да, үземнең хаклыгымны белсәм, сайлаган юлымнан тайпылмыйм. Мине юлдан яздырырга бик авыр. Әлбәттә, киңәшләргә дә колак салам. Кешене тыңлыйм, ләкин үземнекен эшлим.

Бик күпләрдән, мин үземнең нәрсә теләгәнемне белмим, дигәнне ишетергә туры килә. Мин нәрсә теләгәнемне беләм. 12 яшемдә композитор булачагымны, концертлар, спектакльләр өчен музыка язачагымны белә идем. Барысы да ул чакта күзаллаганча чынга ашты. Бервакыт, кызыксынып, бер урамга килеп чыктым. Ә берничә елдан мин шул урамдагы фатирда яши башладым. Холкымның тагын бер үзенчәлеге: мин конфликт яратмыйм, бәхәскә кермим. Кеше шулай уйлый икән, аның үзгә фикергә хакы бар.

:: Иҗади яңалыкларың белән дә таныштырсаң иде.

– Узган елны Россия Президенты Владимир Путинга композиторларга ярдәм кирәклеге турында сөйләгән идем. Ул проблема тиз генә хәл ителә торган түгел, ләкин барыбер ниндидер юнәлешләр барлыкка килде. Хәзер Композиторлар берлеге аша заказга зур күләмле әсәрләр язуга грант отып була. Шушы грант нигезендә орган һәм оркестр өчен концерт язам. Безнең яхшы оркестрыбыз да, Зур концерт залында органыбыз да бар. Шушы уен коралы өчен фестивалебез дә бар. Мин зур академик музыканы бик сагынганмын икән. Соңгы елларда күбрәк җырлар, спектакльләргә музыкалар яздым.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ТУЛЫ ВАРИАНТЫ VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ГҮЗӘЛ ӘДҺӘМ

АЛСУ ТӘРӘЗӘ

(хикәя)

< Ахыры. Башы 1 июль санында

Кайда йөри бу хатын? Аның белән шаярырга ничек җөрьәт итә ул? Фәридәсе шул минутта килеп керсә, (билләһи дип әйтәм) бәргәләп ташлар иде. Әмма Фәридә юк! Юк Фәридә!

«Әллә эшкә алданрак киткәнме? Әтеге язу? Әгәр дә ташлап китүе чын булса? Ничек инде? Булма-аас! Алай булырга тиеш түгел лә!»

Дамир елмаеп куйды.

«Тиеш түгел, канишны! Кара әле мин тилене! Башыма әллә нинди чүп уйлар кереп маташа түгелме?!»

Тагын телефонга ябышты.

Юк! Җавап бирми Фәридә.

«Эшенә шалтыратырга кирәк! Кирәк, билгеле! Ә кайда соң эш номеры?»

Дамир телефонда шактый озак актарынды. Бу номерга соңгы тапкыр кайчан чылтыратканын да оныткан иде. Ярый әле, хатыны декрет ялында дип, номерын алып ташламаган! Ниһаять, тапты!

– Алло! Хәерле иртә! Телефонга Фәридәне чакыра алмассыз микән?

– Нинди Фәридә?

– Зарипова Фәридә!

Теге якта бераз тынып тордылар.

– Әәәә... Зарипова! Ул бездә эшләми бит! Уволилась!

Әллә идән чайкалып китте инде... Дамир әздән генә авып китмәде, сүзләрен дә көчкә генә сытып чыгарды ул.

– Уволилась?.. Ничек... инде? Кайча-ан?

– Декрет ялыннан соң килде дә увольняться итте! Туктагыз әле! Сез нигә миннән сорау аласыз? Сез кем?

Шунда гына исенә төште Дамирның! «Әйтте Фәридә! Яңа эш таптым, диде! Нидер сөйләнде дә кебек... Тик Самираның мәхәббәт утында көйрәгән Дамир гына моны «ишетмәгән» булып чыкты! Фәридәнең кайда эшләвен дә белми хәтта! Позор!»

Улы Ринат чалбар балагыннан тартты.

– Әти! Мәктәпкә соңга калабыз... Светлана Николаевна...

– Нинди мәктәп тагын! Мин эшкә соңга калам! Кайда бу анаң?!

Катырак кычкырдымы, Ринат елап җибәрде. Аңа кечкенәсе дә кушылды.

Фәридә һаман «недоступен!»

«Нишләргә? Эшкә киткәнче, башта бу елаклардан арынырга кирәк бит. Ринаты инде әзер, портфелен тотып ишек төбендә басып тора. Ә менә Данилны кем киендерә?» Трусик-майкадан басып торган ялананяклы улына Дамир яратмыйча карап куйды.

Дөньяда ир-ат өчен бала киендерүдән дә авыррак, мәшәкатьлерәк эш бар микән? Мөгаен, юктыр. Дамир тирләде, пеште, мышнап чыкты. Ярый әле, Ринаты ярдәмгә килде. Юкса әти кеше үзе генә бу бөек миссияне ырып-ерып чыга алмас иде...

Кинәт телефон аваз салды.

Дамир бар көченә трубкага акырды:

– Фәридә! Син кайда йөрисең?

Анда исә берәү чыркылдап көлде:

– Мин Фәридә түгел, Дамир Хәсәнович! Мин – Эльза! Сез кайда? Шеф сезне юллый!

Сәгатькә караса, сигез тулып киткән!

«Уууу-ффф!!! Ү-ләәмм!»

...Бераздан Дамир ике елак малайны җилтерәтеп подъезд төбендә басып тора иде.

– Мәктәбең кайда?

«Ярый әле мәктәбе янәшәдә генә!» – дип сөенгән иде Фәридә. Малайның укый башлавына икенче ай китте, ә Дамирның әлегә улын озатканы да, каршы алганы да булмады. Дөрес, Фәридәсе беренче сентябрьнең шимбә көнгә туры килүенә бик куанган иде.

– Ринатны мәктәпкә бергәләп озатабыз! Бөтен гаилә белән барыйк әле, – дип сөенде хатын.

Тик Дамир гына:

– Шеф чакыра! Тузгый! – дип, машинасына утырып шылды.

Дөресе, Самира-гүзәлкәйне Тура базарына алып барды ир.

«Янәшәдәге» дигән мәктәпне эзләп табып, Ринатны тапшырганчы, җиде кат тирен түкте Дамир. Җитмәсә, минут саен эшеннән шалтырататалар! Ярый әле, анда хәленә керделәр.

– Хатын авыр хәлдә, скорыйда больницага барабыз! – дигән ялганына ышанып, юатып та маташтылар, соңга калырга рөхсәт тә иттеләр.

Ниһаять, теге елак Данил белән икәү генә басып калды Дамир. Анысы исә елак кына түгел, аңгыра да икән!

Бары тик ниндидер кәгазь кисәге генә ята.

Түгәрәк-түгәрәк хәрефләр яңа хәбәр җиткерде: «Дамир! Машина миндә! Фәридә».

Бу чып-чын катастрофа иде!

...Эшенә төштән соң гына барып җитте ул. Андагылар Фәридәнең «авыр хәлдә» булуына борчылдылар, агарып калган, сулган ирне кызгандылар, ярдәмнәрен тәкъдим иттеләр. Күп тә үтмәде, телефонына да җан керде.

«Фәридә!»

Ниндидер таныш түгел номер шалтырата икән.

– Здравствуйте! Вы папа Рината?

– Да...

– Я – Светлана Николаевна, учительница вашего сына. Хочу вас предупредить, сегодня у нас короткий день. Жду вас в два часа!

«Туктале! Бу нәрсә була соң? Дамир нишләргә тиеш?»

– Садигың кайда? – дигән сорауга аңгыра сарыктай караган да каткан.

Дамир аны җилтерәтә үк башлады:

– Кайсы садикка йөрисең? Күрсәт!

Тиле дими, ни дисең инде аны! Өч яшен тутырган, ә садигына бара да белми! Югыйсә ике ай йөри бит инде!

Шунда исенә төште: «Ринаттан сорарга кирәк!»

Данилны күтәреп, кире мәктәпкә чапты – ә анда кертмиләр!

– Рөхсәт юк! – дип, сакчы формасы кигән берәү аркылы баскан.

«Нинди дөнья соң бу! Ничек яшәргә була шушы мәхшәрдә!»

Дамир үзе дә, теге аңгыра малайга ияреп, чүт кенә елап җибәрмәде.

– Ну, Фәридә! Кайт кына! Бирәм кирәгеңне!

Фәридә «недоступен!» Кинәт хатынының бер сүзе хәтердә яңарды!

– Данилларның уен мәйданчыгы безнең тәрәзәдән шундый яхшы күренә. Бүтәннәр белән аралашамы дип карап тордым, дуслар да тапкан безнең төпчегебез.

Кире өйләренә чапты – сигезенче каттан яхшырак күренә ди бит!

Ни арада лифтны сүндереп куйганнар! Данилны күтәреп, сигезенче катка менеп җиткәндә, Дамир туксан тапкыр сөртенде һәм йөз тапкыр сүгенде.

«Барысы да шушы Фәридә аркасында! Ну-уу! Кайт кына!»

Кухня тәрәзәсеннән карасаң – бер балалар бакчасы, ә залныкыннан икенчесе күренеп тора икән.

«Ике якта – ике садик! Я, ни пычагыма кирәк инде шулкадәр садик бу районга?!» Дамир тагын сүгенде.

Бәхеткә, өч яшьлек сабый агачлар арасыннан күренеп торган зәңгәр түбәле бер бинага төртеп күрсәтте:

– Это – мой садик!

«Тизрәк бу малайны олактырып, эшкә чабарга кирәк!»

Тиз-тиз генә үзен тәртипкә китерде дә ишек янындагы ачкыч савытына үрелде. Тик машина ачкычы анда юк булып чыкты. Шунда гына салды бит! Кая киткән? Кем алган? Ачкыч савытын әйләндерде-тулгандырды, какты-селекте. Юк булгач – юк инде! Анда

Алдын-артын карамый чыгып йөгергән ир артыннан кызганып карап калдылар.

...Автобусларда кысыла-кысыла, трамвайдан-трамвайга күчеп килеп җиткәндә, сәгать инде өчне тутырып килә иде. Светлана Николаевна дигәннәренең дә йөзе-чырае каралган, канәгатьсезлеген белдереп, башын чайкап куйды.

– Прошу больше не опаздывать!

Малайның да борыны салынган, сөйләшмичә, күңелсез генә өйгә кайттылар.

Нәрсә дә булса эшләргә кирәк иде! Тик нәрсә? Фәридә бит «недоступен!» Авылдагы әби-бабайга, Фәридәнең туганнарына шалтыратыр иде – ник берсенең номерын белсен! Әллә телеграмма сугаргамы? Тик нәрсә дип? Фәридә мине ташлап китте дипме? Юк инде! Үлсә үлә Дамир, әмма серне чишмәячәк! Хурлыгы ни тора! Түзәргә туры килә инде...

– Әти, ашыйсы килә...

Рәхмәт төшкере, кичәге «кызыл аш» икесен дә ач үлемнән йолып калды.

– Рәхмәт, әти...

Ринаты кран астында тәлинкәләрне юып маташа. Дамир аңа шаккатып һәм сәерсенеп карап куйды.

«Кемнән өйрәнгән бу малай эш тәртибенә?»

Улы, тәлинкәләрне урнаштыргач, кулларын юды да өстәл янына килеп утырды, портфеленнән дәфтәрләрен алып нидер яза башлады. Яза. Тырыша-тырыша хәреф тезә: «и», «ш», «м» хәрефләре... Телен чыгарып, иреннәрен ялый-ялый яза улы. Үзенең беренче сыйныфта укыган чакларын исенә төшерде Дамир. Ул да шундый иде: иренен ялап, язып утырган бер фотосы әле дә саклана. Тик язуы матур түгел иде шул, «өчле»дән башы чыкмады.

«Ә малай... минем улым нинди билгеләр ала микән?» Дәфтәрен ачып карап чыкты. Тагын бер гаҗәпләнгәнгә шул булды: хәзер билге куймыйлар, ахры. «Бишле», я «дүртле» алса, улы сөенгән булыр иде. Юк, билге куймаганнар. Бераздан Дамир «Менә бит!» дип кычкырып җибәрде. Дәфтәрнең иң пөхтә битенә кызыл кара белән «Молодец!» дип язылган иде. Улының беренче билгесе була бит инде әлеге «Молодец!»

Дамир тагын көлде, малайның ябык тәнен үзенә кысты.

– Молодец, улым!

– Минем «Молодец!»ларым тагын бар, әти! Менә монда... Монда да...

Телефон тавышы аларның әңгәмәсен бүлде. Икесе дә сикереп торды:

– Әни!

– Фәридә!

Самира икән...

– Любимый, это что? Не понимаю!

Самираның канәгатьсез, шелтәле тавышы Дамирның фикерен чуалтып җибәрде.

– Самира, тыңла әле...

– Еще чего? Мы же договорились!

Шактый озак аңлашырга туры килде аларга. Самира тыңларга да, килешергә дә теләмәде, ахырда үпкәләшеп туктадылар.

– Әти, сәгать ничә ул?

– Сәгать? Нәрсәгә сиңа сәгать?

– Әни гел: «Данилны садиктан биштә алырга кирәк», – ди.

Аталы-уллы бакчага йөгерде.

Соңыннан алар өчәүләп таган атындагы кафега кереп ашап чыктылар, кибеттән ипи-сөт һәм манный ярмасы алды Дамир. Студент чагында тәмле пешерә иде ул манный боткасын, улларын да сыйласын әле...

Фәридә кайтмады, һаман да «недоступен»...

Самираның үпкәсе бик көчле булды, ахры, ни үзе шалтыратмый, Дамир шалтыратса, трубканы алмый...

– Әни-иии!

Төнлә Данил елап уянды. Әллә саташа инде? Әллә куркыныч төш күргәнме? Дамир торды, уларын йокы бүлмәсендәге киң караватка күчерде, үзе аларның уртасына ятты. Әле һаман сулкылдаган Данилның йомшак чәчле башың күкрәгенә кысты ул. Малай нәни куллары белән әтисенең муеныннан кочаклап алды, үзе йокы аралаш нәрсәдер бытылдады. Сабыйның чәченнән башны әйләндергеч тәмле ис килә иде... Шундый таныш, якын ис... Фәридәнең чәч исе...

...Аннан соңгы бер атна бик тиз үтте. Дамир ял алды, малайларның берсе мәктәпкә, икенчесе бакчага йөрде. Самира белән аралары гел бозылышып бетте. Ахырда кыз түзмәде, Кара диңгез буена ялгызы очты. Икенче путевканы да үзе белән алуны кирәк тапты. Кем белә: бәлки ялгызы каңгырап йөргән берәр «иптәш» очрап куяр!

...Цирктан алар караңгы төшкәч кенә кайтып җиттеләр. Дамир һәм ике улы... Өчесе дә шат һәм бик бәхетле иде. Дамир, башын күтәреп, сигезенче катка күз салды.

Анда! Ә анда исә алсу тәрәзә балкый иде!

Әз-мәз мәзәк

«Майкрософт» компаниясе Россия халкына рәсми сайттан виндоус программасын күчереп алуны тыйды. Шул рәвешле Россия халкы «Майкрософт»ның рәсми сайты бар икәнен белде.

* * *

Ике черки сөйләшә:
– Даа, малай, хәзер кешеләр элеккеге түгел шул инде. Гел химия!

* * *

Быел Нобель премиясен үле кешеләрне терелтә белүче биологка бирделәр. Альфред Нобель сәхнәгә менеп, аны шәхсән котлады.

* * *

Рөстәм базарда кавын сатып алгач, аны үзенең хатынына – ядрә ыргыту буенча спорт мастеры Мәрьямгә тотып торырга биргән. Алай итәсе калмаган.

* * *

Зоопарктa игълан: «Эшкә кассир чакырабыз. Хатын-кыз җенесеннән булсын».

* * *

Россия спортчысы үзенең командасына алтын медаль алып килгән. Каян алган ул аны – берәү дә белми.

* * *

– Бүгенгә нинди планнар?
– Иртәдән офтальмологка барам.
– Ә аннары?
– Ә аннары күз күрер.

* * *

Почтада бер мәзәк сөйләгән идем – бик озак барып җитте.

* * *

– Матурым, күрше тавыклары безнең бакчага керми башлады. Нишләттең син аларны?
– Башта бакчага йомыркалар тараттым. Аннары шуларны күрше күз алдында җыеп чыктым.

* * *

Мин элек үземне программист дигәч, танышларым мине виндоус куеп бирергә сорыйлар иде. Аннары үземне «архитектор баз данных» дип таныштыра башладым. Башта югалып калдылар. Аннары бакчага баз проектын ясап бирергә сорый башладылар.

* * *

– Минем кер юу машинасы инде 15 ел эшли. Амортизаторларын гына алыштырдым.
– Әйе, юлларның рәте юк шул бездә.

* * *

Безнең мәктәптә ике тәрәзә бар иде. Тимер читлеге булганы – терроризмга каршы. Тимер читлеге булмаганы – янгын куркынычсызлыгы өчен.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Зәйтүнә, Ибраһим, Нәҗип, КрАЗ, га, ау, Анри, лимузин, Арча, иләк, эссе, йон, Сукояр, су, Масяня, ел, әнә, Янсуар, Ди, рарирет, ки, әбәк, Буа, Иа, рәшәткә, Наласа, си, ял, Хәлил, Ык, ля, Миңнуллина, Мансур.

Вертикаль: Зәйдулла, Мәрәтхуҗа, Ан, Мәйсәрә, оя, акр, Зиннур, ил, әнкәй, Нәс, үтмәс, хыял, әр, ку, тирәк, аҗаган, Квят, Изаура, бәя, Ла, ИП, ир, Лилия, чардуган, эсер, сул, Киа, Диас, Миләшкәем, Адымнар.

Беләсең килсә...

1 Коми башкаласы Сыктывкар шәһәре тарихы Әби патшаның 1780 елгы карарыннан башлана. Элек аның аталышы болай булган:
а) Усть-Илимск;
б) Усть-Сысольск;
в) Усть-Каменогорск.

2 КамАЗ логотибында аргамак сурәте ничәнче елда барлыкка килгән?
а) 1969;
б) 1988;
в) 1991.

3 Әлеге әдәби премия 1981 елда бирелә башлый:
а) Шәйхи Маннур премиясе;
б) Саҗидә Сөләйманова премиясе;
в) Муса Җәлил премиясе.

4 Бу уенны 1895 елда физкультура укытучысы Уильям Морган уйлап тапкан.
а) баскетбол;
б) волейбол;
в) пионербол.

Җаваплар: 1) б; 2) б; 3) а; 4) б.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16052 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 296

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+